## ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ!

Яшел Үзәндәге Әйшә авылында 100 йортка газ бушлай тоташтырылды

> 2

## ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

«Әдәбиятка каршы сугыш ачарга ярамый: бу үз күңелеңне үзең киту кебек»

> 2

## ЧЫН БЕЗНЕҢЧӘ

Онытылып баручы көйләрне дә яңача яңгыраштa ишетергә мөмкин

> 5

## ХА-ХА-ХАНӘ

Кызык-мызык, булмас димә, фототөрткеләр – монда

> 6


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 167 (28940) | Шимбә | 12 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131


# ЯҢАРТЫП АГАРТУ

## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНДА МӘДӘНИЯТ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ БҮГЕНГЕ ХӘЛЕ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕЛӘР

**Узган ел республиканың мәдәни оешмаларына барлыгы 23 миллионнан артык кеше килгән. Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында мәдәният оешмаларының бүгенге хәле, проблемалары хакында сөйләштеләр. Авыл клубларында да хәл итәсе мәсьәләләр шактый әле. Интернеты да, белгечләре дә кирәк, хисап эше дә күп...**

tatarstan.ru

### Клубларда ни хәл?

Татарстан мәдәният министры урынбасары Юлия Әдһәмова белдергәнчә, республикада клублар каршында эшли торган берләшмәләр саны 2020 ел белән чагыштырганда 37гә кимегән. Бу пандемия вакытында кертелгән чикләүләргә, шул исәптән 65 яшьтән өлкәнрәк кешеләр өчен үзизоляция режимына бәйле. «Әмма бу күрсәткеч, быелгы нәтиҗәләр буенча, барлык чикләүләр бетерелгәч тигезләнер дип өметләнәбез. Өлкән буын – безнең төп аудиторияләрнең берсе», – диде урынбасар. Кыенлыкларга карамастан, Татарстан клублар саны буенча Россия төбәкләре арасында беренче урында тора.

Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе урынбасары Людмила Рыбакова белдергәнчә, депутатлар республикадагы 119 мәдәният йортында булып, аларның хәле белән танышкан.

– Мәдәният йортлары 1937–2020 елларда төзелгән. Президент программасы ярдәмендә хәзер яңа клублар төзелә, искеләре төзекләндерелә. Шулай да 119 объектның 46сы төзекләндерүгә мохтаҗ. Хәтта яңа клубларда да кайдадыр сәхнә костюмнары, җиһазлар җитми. Мәдәният учреждениеләрендә техник базаны арттыру өчен бюджетта аерым бер программа булдырырга кирәк, – диде ул.

Бу уңайдан фикер алышуда катнашкан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе җитәкчесе Марат Әхмәтов:

– Кайбер мәдәният биналары начар хәлдә булса да, аларның эшеннән хилафлык эзләргә кирәкми. Җиһазлар бар җирдә дә бар, тик без теләгәнчә үк камил булмаска мөмкин. Бу очракта кешеләрнең үзара мөнәсәбәте матур нәтиҗә бирергә тиеш. Әле беркайчан да интерактив җиһазның үзара аралашуны алмаштыра алганы юк, – диде.

### Белгечләр җитми

2022 елның 1 гыйнварына китерелгән мәгълүматлар буенча, мәдәният учреждениеләрендә эшләүчеләр саны – 8808. Шул ук вакытта Россия һәм Татарстан мәдәният йортларында аккомпаниаторлар, халык һәм тынлы уен кораллары ансамбльләре җитәкчеләре, режиссерлар, тавыш инженерлары җитми.

Казан дәүләт мәдәният институты (утырыш та шунда узды. – **Ред.**) ректоры, парламент комитеты каршындагы Экспертлар советы рәисе Роза Әхмәдиева мәдәният йортларындагы кыенлыкларны, ягъни кадрларның эштә төпләнеп калмавын, матди-техник яктан тәэмин ителеш җитмәүне эшчәнлекне оештыруның яңа формалары булмаудан күрә. Моның өчен ул белгечләрне алдан укыту системасын оештырырга, оешмаларның матди-техник базасын ныгытуны камилләштерергә, мәдәният хезмәткәрләренә ярдәм күрсәтүне активлаштырырга тәкъдим итте.

Утырышта Качалов театрының сәнгать җитәкчесе Александр Славутский театрларның мәдәният йортлары белән эшләве җитмәвен әйтте. Аның сүзен депутат Альбина Насыйрова да куәтләде: «Мин барган клубларда да, без чакырабыз, театрлар килми, диделәр. Сәбәбе бер генә түгел. Билет бәясенең түбән булуы, бер генә грим бүлмәсе, салкын бина... Шуңа безнең театрлар килергә ризалашмыйлар. Авыл клубы чакыра икән, теләкләрен тормышка ашырырга кирәк».

### Интернетсыз эш бармый

Мәдәният министры урынбасары Юлия Әдһәмова мәдәният йортларын интернетка тоташтыру мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьләр күп килүен әйтте. Интернетка тоташу мөмкинлеге булган мәдәни-ял итү тибындагы оешмалар нибары 20,1 процентны тәшкил итә. Шәхси компьютерлар һәм автоматлаштырылган эш урыннары саны – 1832. Ул әлеге уңайдан Татарстан Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына район мәдәният учреждениеләренә кирәкле җиһазлар алу, рәсми сайтлар булдыру турында хат җибәрелүен әйтте.

Ахыры 2 нче биттә >

**Сан**

Республикада 1909 мәдәни оешма бар. Узган ел 466 мәдәният йортына ремонт кирәк булган, 18е авария хәлендә дип табылган. 2012–2021 елларда авыл җирлекләрендә 50дән 300гә кадәр кеше сыйдырышлы 331 күпфункцияле үзәк төзелгән. Узган ел Кукмара районында Аш-Буҗи, Чишмәбаш һәм Минзәлә районының Коноваловка авылы халкы яңа клубларга тиенгән. Сүз уңаеннан, авыл җирендә барлыгы 13469 клуб эшли, 208 меңнән артык кеше төрле чараларда катнашкан.

# РКБ тулысынча цифрлашты

Республика клиник хастаханәсе HIMSS (дөньяда медицина өлкәсен мәгълүматлаштыру сыйфатын бәяләүче бердәнбер оешма) стандартларына туры килүче цифрлы клиника буларак танылган. Хастаханәнең матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, узган елның ноябрендә республика клиникасында цифрлы революция үткәреп карарга булганнар. «Чор сынавы, республикабызның үсеш этабы сынавы бу. Цифрлаштыру елында Сәламәтлек саклау министрлыгы тәкъдиме нигезендә Цифрлы үсеш министрлыгы белән республика Президенты исеменә клиниканы цифрлаштыру тәкъдиме белән мөрәҗәгать әзерләнде», – ди РКБ баш табибы Рафаэль Шәвәлиев.

Проект Татарстан Сәламәтлек саклау һәм Цифрлы үсеш министрлыклары ярдәмендә тормышка ашырылган. Шулай итеп, РКБ Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы структурасында сертификация узуга ирешкән тәүге клиникага әйләнгән. Сүз уңаеннан, МЧС карамагындагы хастаханәнең илебездә беренче тапкыр үзенең HIMSS таләпләренә туры килүен раславын әйтеп үтик.

Хәзер РКБда кәгазьдән тулысынча баш тартканнар диярлек. Табибларга авыру тарихларын тутырырга кирәкми, дигән сүз бу. Димәк, кемнеңдер ялгыш язуы аркасында килеп чыккан табиб хаталарына да урын калмаячак.

# *Гаражларны бушлай теркиләр*

Росреестрның Татарстандагы идарәсе, «Гараж амнистиясе турында» законны тормышка ашыру кысасында, 2021 елның 1 сентябреннән быелгы 30 октябрьгә кадәр 2500 гараж һәм 2250 җир кишәрлеген теркәгән. «Гараж амнистиясе»н бигрәк тә Казан һәм Чаллыда яшәүчеләр үз иткән: 14 ай эчендә бу шәһәрләрдә 1090 һәм 1038 объект теркәлгән. Шулай ук Әлмәт (957 объект) һәм Чистай (496) халкы да амнистия мөмкинлекләреннән әйбәт кенә файдаланган. Шулай итеп, Росреестр идарәсе җитәкчесе Азат Җәббаров әйтүенчә, «амнистия»нең бер елдан артыграк гамәлдә булуы чорында республикада 4759 күчемсез милек объекты теркәлгән. Татарстан әлеге күрсәткеч буенча лидер төбәкләр бишлегенә керә.

Гаражны һәм җир кишәрлеген бушлай рәсмиләштерү максатында, җирле үзидарә органына гамәлдәге гараж өчен җир кишәрлеге бирү турында гариза һәм гаражга ия булуны раслаган теләсә нинди документ тапшырырга кирәк. Гараж кооперативында пай түләү турында документ, гараж бирү турында карар, техник инвентаризация документлары һ.б. булырга мөмкин бу.

# *Бурыч түләмәсәң, бил бөгәсең*

Нурлатта 46 яшьлек ир, 780 мең сумлык алимент бурычын түләтү йөзеннән, мәҗбүри эшләргә җибәрелә. Баласын карауга акча бирмәгән өчен аңа шундый хөкем карары чыгарылган. Татарстан прокуроры өлкән ярдәмчесе Руслан Галиев әйтүенчә, битараф ата быел июльдән сентябрьгә кадәрге чорда сабыйга ярдәм итмәгән. Инде элегрәк тә алимент түләмәгән өчен җавапка тартылганы булган. Шулай итеп, гомуми бурычы күләме 780 меңнән артып киткән.

Суд, хезмәт хакының 10 процентын дәүләт файдасына тотып, ирне 10 айга төзәтү эшләренә җибәрү турында карар чыгарган.

**Хәрәкәт иминлеге**

# Ялгышларны кичерми

**Һәлакәтләр саны кими, аларда үлүчеләр саны арта. Республика юлларындагы быелгы вазгыятьне кыскача гына шулай бәяләп була. Бу хакта журналистларга Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы Дәүләт автоинспекциясе идарәсе башлыгы Рөстәм Гарипов хәбәр итте.**

Быелның гыйнвар – октябрь аралыгында Татарстан юлларында барлыгы 2760 юл һәлакәте килеп чыккан. Аларда 256 кешенең гомере өзелгән, 3386 кеше имгәнгән. Юлларда килеп чыккан һәлакәтләр саны узган ел белән чагыштырганда 257 очракка азрак булса да, гомере өзелгәннәр саны бишкә күбрәк. Рөстәм Гарипов белдерүенчә, мондый фаҗигаләр гади генә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәмәү аркасында килеп чыга. «Куркынычсызлык каешы турында онытырга ярамый. Машинага утырган һәркем, иң беренче эш итеп, каешын эләктерергә тиеш», – ди ул.

Быелның ун аенда республика юлларында балалар катнашында 364 юл һәлакәте килеп чыккан. Аларда 11 сабыйның гомере өзелгән. Узган елның шушы чорында балалар катнашындагы юл һәлакәтләре саны 15 очракка күбрәк булган. «Юлларда балалар гомере өзелү – бөтен җәмгыять өчен зур хәсрәт. Төп җаваплылык без – өлкәннәр өстендә. Ун ай эчендә балаларның игътибарсызлыгы аркасында 110 юл һәлакәте теркәлде. Әмма бу очракта аларны гаепләп булмый. Димәк, без бу юнәлештә тиешенчә эшләп җиткермәгәнбез, аларга юлда үзеңне ничек тотарга кирәклеген яхшылап аңлатмаганбыз дигән сүз», – диде идарә башлыгы.

Рөстәм Гарипов балаларга мотоцикл ише «үлем уенчыклары» алып бирүнең дә ни дәрәҗәдә куркыныч икәнлеген искәртте. Хәтерләсәгез, җәй көне Биектау районында әти-әнисе улына туган көненә мотоцикл бүләк итә. Малай исә шул ук көнне туктап торган машинага бәрелеп үлә. Алабугада да шундый ук фаҗига килеп чыга. Анда мотоцикл белән идарә иткән яшүсмер автобуска килеп бәрелгән. «Ата-аналарга тагын бер кат мөрәҗәгать итәсем килә. Йөртү таныклыгы булмаган балагызга мондый «үлем уенчыгы» бүләк итә күрмәгез!» – ди идарә башлыгы.

Җәяүлеләрдән дә игътибарлырак булу сорала. Рәсми саннардан күренгәнчә, ел башыннан бирле Татарстан юлларында 790 җәяүлене таптатканнар. Чагыштыру өчен: узган ел шундый 822 очрак теркәлгән булган. Бу фаҗигаләрнең күбесе җәяүлеләрнең игътибарсызлыгы, юлны тиешсез урыннан чыгуы аркасында килеп чыга. Юлдан чыкканда телефонга текәлеп бару, колакчыннан музыка тыңлау да еш кына әнә шулай аяныч тәмамлана. Җәяүлеләр гаебе белән 294 юл һәлакәте теркәлгән, 49 кешенең гомере өзелгән.

Машина йөртүчеләр авызыннан еш ишетергә туры килгән тагын бер мәсьәләгә дә ачыклык кертте җитәкче. Яшерен-батырын түгел, күпләр ЮХИДИ хезмәткәрләренең юл һәлакәте булган урынга озак килүеннән зарлана. Рөстәм Гарипов исә үлем-китем, имгәнүләрсез узган җиңелчә юл һәлакәтләрен евроберкетмә ярдәмендә рәсмиләштерергә киңәш итә.

– Һәлакәткә очраган машинаны вакытында юлдан алырга кирәк. Юкса, трассада гына түгел, хәтта шәһәр эчендәге башка машина йөртүчеләр дә туктап өлгерә алмыйча, тагын да зуррак фаҗига килеп чыгарга мөмкин, – ди җитәкче.

Һавадан алып әйтелгән сүзләр түгел бу. Күптән түгел генә М7 трассасында юл һәлакәтенә очраган бер туташны аварияле тукталыш билгесе куйганда машина бәреп киткән. Хәзер ул авыр хәлдә хастаханәдә ята.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

**Сүзгә-сүз**



**Юлия БУЛАТОВА, Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсе җитәкчесе урынбасары:**

Ташламалар, дисәләр дә, кайберәүләр теге яисә бу товарның бәясен алдан махсус күтәрә дә, көне килеп җиткәч, кабат төшерә. Сатып алучы өчен ул отышлы бәя булып тоела. Акция вакытында сатып алынган товарны алыштырып яки кире тапшырып булмый, диючеләр дә бар. Алар кулланучылар хокукларын яклау турындагы законны боза. Акциягә эләккән товарларны, нәкъ башка товарлар кебек үк, алыштырып та, тапшырып та була.

**(Журналистлар белән очрашуда сөйләгәннәрдән)**

# СЕЗ ЭШЕГЕЗДӘН КАНӘГАТЬМЕ?

**Head Hunter хезмәте Татарстан халкына әнә шул сорауны биргән. Сораштыруда катнашучыларның күп өлеше хезмәт урыннарыннан туюларын әйткән.**

**44%** – канәгать түгел
*(юрист, хисапчы, транспорт тармагы хезмәткәрләре)*




# Арзангарак алып кал

Бүген Казанда авыл хуҗалыгы ярминкәләре уза. Сәүдә иртәнге 6дан көндезге 12гә кадәр 15 мәйданчыкта гөрли. 22 районнан килгән фермер һәм 18 авыл хуҗалыгы оешмасы шәһәрдә яшәүчеләргә үзләренең продукциясен тәкъдим итә.

Татарстан башкаласы мэриясе матбугат хезмәте хәбәренә караганда, Казан халкы бер ярминкә көнендә бөтен мәйданчыкларда барлыгы якынча 48,5 миллион сумлык продукт сатып ала. Шикәр комы, бәрәңге, он, йомырка һәм яшелчәгә ихтыяҗ бигрәк тә зур.

Илдар Мөхәммәтҗанов

## ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Марат КӘБИРОВ

# Әдәбиятка каршы сугыш

Быел җәй азакларында Украинаның Мәгариф һәм фән министрлыгы чит ил әдәбиятын укыту тәртибенә үзгәрешләр кертте: аннан Россия авторларының әсәрләрен алып ташлады. Рус әдәбиятының Украинада туган вәкилләре өчен генә искәрмә ясалды. Сүз Николай Гоголь, Владимир Короленко, Михаил Булгаков турында бара. Бу хакта 16 августта Украина Мәгариф министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр итте.

«Россия авторлары урынына украин укучылары дөнья язучыларының шедеврларын өйрәнәчәк», – дип белдерә матбугат чаралары. Бу җөмлә бик сәер яңгырый. «Нәрсә, Җир шарының зур гына бер өлешен биләгән Россия дөньяга кермимени?» дигәнрәк сорау туа. Дөнья әдәбияты булгач, бөтен илләрне берләштерә торган әдәбият ич инде ул. Монда барысы да керә.

Без һәрвакыт татар әдәбиятын үгисетергә күнеккәнбез. «Һи, татар язучыларының укырлык китабы бармыни!» – дип җиппәрәләр үзләренең наданлыгын өстенлек итеп күрсәтергә омтылучылар. Ләкин мондый рухи имгәкләр бер татарда гына түгел, башка халыкларда да җитәрлек икән. Алар хәтта русларда да бар. Күбрәк тә икән хәтта. Менә моның сәбәбе инде халыкның үзендә генә түгел.

СССР таркалган чорларда Борис Ельцин (егерме яшьлекләр өчен махсус искәрмә: Россиянең ул чактагы Президенты): «Мәдәният көтеп торыр», – дигәнрәк сүз әйткән иде. Әлбәттә, аңа карап кына мәдәният тә, әдәбият та кул кушырып, нидер көтеп утырмады. Әмма әдәбиятны дөньяга таныту өчен Россиядә бернәрсә дә эшләнмәде, диярлек. Дөньяга түгел, үз дәүләтенә таныту буенча да хакимият әһелләре кыл да кыймылдатмадылар. Ләкин изге урын буш тормый. Укучылар күңеленә чит ил әдәбияты үтеп керде. Бу ул әдәбиятның шедевраль булуыннан бигрәк бертуктаусыз эшләгән пропаганда һәм реклама нәтиҗәсе иде. Америкада, мәсәлән, нинди китап бестселлерга әверелә, шуның буенча фильм яки сериал төшерә башлыйлар. Китап сәүдәсе аз гына түбәнәя башлый икән, кино мәйданга чыга да теге китап белән кызыксынучылар тагы күбәя. Китаплар да, фильм-сериаллар да, шул арада ук чит телләргә тәрҗемә ителеп, бөтен дөньяга тарала. Бу шултиклем өзлексез эшли торган механизм кебек җайланган, мәңгелек двигатель шикелле. Ул үз нәтиҗәсен бирә: бөтен Россия халкын үз мәдәниятенә, үз әдәбиятына икенчел итеп карарга мәҗбүр итә.

Татар зыялылары да еш кына: «Дөнья әдәбияты биеклегенә күтәрелү», «Дөнья әдәбиятын яулау», – дигән сүзләр ычкындыра. Бу – буш сүзләр. Сафсата. Дөнья әдәбияты бар һәм бербөтен: анда татарныкы да, русныкы да, инглизнеке дә, французныкы да, үзбәкнеке дә, японныкы да, башка халыкларныкы да керә. «Дөнья әдәбияты биеклегенә күтәрелү» дигәнне ишеткәндә, мин сәер бер күренешне күз алдына китерәм. Иртән уң аягың телгә килә: «Мин баш дәрәҗәсенә күтәрелергә телим!» – дип ярып сала ул. Ә башның теләге – аяк кебек йөгерек эшли алу, аның аяк дәрәҗәсендә гади дә, гали дә буласы килә. Кич җитүгә, боларның теләкләре чынга аша. Аяк баш урынына менә, баш аяк урынын ала. Гариплекне, аның нәтиҗәсен күз алдына китерәсездер инде? Дөнья әдәбияты да кеше организмы кебек үк бербөтен. Һәр әгъзасы кирәкле һәм үз урынында. Татар әдәбияты да үз урынында. Ул үз юлыннан үзе күтәрелә. Аны күтәрергә кирәкми, аны танытырга кирәк. Мин чит ил әдәбияты белән даими танышып барам, шуңа бер курыкмыйча әйтә алам: «бестселлер» дип танылган әсәрләрнең күбесе – пүчтәк нәрсә. Китаплары миллионнарча данәдә сатылган авторларның күбесе хәтта миннән дә начаррак яза. Мин, мәсәлән, алар дәрәҗәсенә «күтәрелергә» теләмим. Ләкин чит илләрнең таныту ысулы яхшы көйләнгән: алар укучыларны уч төбендә тота һәм беркадәр сәләте булган теләсә кайсы авторны «модный»га әйләндерә ала.

Әгәр Россия җитәкчелеге үз вакытында әдәбиятка тиешле игътибар биргән булса, бүген ул иң тәэсирле көчләрнең берсенә әйләнер иде. Ул вакытта инде рус әдәбиятын мәктәп программаларыннан төшереп калдыру турындагы уй беркемнең дә башына килә алмый. Бу урында инде миндә тагы берничә сорау туа. Ә безнең рус мәктәпләрендә укучы балалар татар язучыларының иҗаты белән таныша микән? Алар безнең ничә язучыны белә икән? Югыйсә бүген Язучылар берлегендә өч йөздән артык автор исәпләнә, шуларның ким дигәндә, утызының иҗаты бөтен дөньяга танылырлык. Мохтаҗлык туганда Россиянең иминлеген яклашучы башка халыкларның әдәбиятын белә микән рус мәктәпләрендә укучылар? Ватандаш халыклар иҗатына булган битарафлык үз әдәбиятыңның да дәрәҗәсен төшерми микән? Тик бу сорауларны кычкырып әйтмим. Үземдә генә саклыйм. Ә әдәбият тирәсендә ыгы-зыгы һаман дәвам итә.

Яңарак кына (02.11.2022) Украина матбугатында әдәбиятка бәйле тагы бер вакыйга турында хәбәр иттеләр. Луцк шәһәрендә Россия авторларының китапларын җыюны оештырганнар. Шәһәр халкы совет чорында чыккан китаплардан башлап бүгенге заман авторларыныкына кадәр бөтен рус китапларын туплап китергән. Ун көн эчендә 600 кг китап җыелган.

Бу китапларны беркем дә укырга җыенмый инде. Барысын туплап, кипкә әйләндерәләр дә макулатурага тапшыралар. Украина заводларында рус китапларыннан бәдрәф кәгазе ясаячаклар, дип хәбәр итә электрон газеталарның берсе. Ә макулатура тапшырудан кергән акча хәрби ихтыяҗларны канәгатьләндерүгә китәчәк икән.

Мондый чаралар һәм аларны матбугатта кирәгеннән артык күпертеп күрсәтү Россиядә яшәүче халыкларга да, украиннарга да файдага түгел инде. Беткә үч итеп, тун ягу кебегрәк нәрсә. Тик ул бүгенге җәмгыятьнең рухи зәгыйфьлеген күрсәтә. Үз-үзен китаптан мәхрүм итәргә тырышкан кавемнәрнең киләчәктә тагын нинди ахмаклыкларга барып төртеләчәген дә күз алдына китерү мөмкин түгел. Әдәбиятка каршы сугыш ачарга ярамый: бу үз күңелеңне үзең китү кебек.

Үзем күрдем

# «Рәхәткә чыктык»

## Әйшә авылында 100 йортка газ килде

**Кичә Яшел Үзән районының Әйшә авылында 100 йорт зәңгәр ягулыкка тоташтырылды. Йортларга газ җибәрү тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Йортларның кайберләре әле төзелеп кенә килә.**

«Газпром трансгаз Казан» матбугат хезмәте

Дүрт урам халкына бәйрәм. Алар әле дә өйләренә газ килгәнгә ышанып бетмиләр. «Урамыбызга бәйрәм килде», – диләр. Рөстәм Миңнеханов исә, бәйрәм белән котлап, ихлас теләкләрен җиткерде.

– Бүген – истәлекле көн, – диде Президент. – Газлаштыру программасы Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча тормышка ашырыла. Без аңа моның өчен бик рәхмәтле. «Газпром» оешмасы җитәкчелегенә дә рәхмәтебезне җиткерәбез.

Рөстәм Миңнеханов Татарстанның төп газлаштыру эшләрен 2000 нче елларда башкаруын, хәзер инде яңа салынган йортларга зәңгәр ягулык тоташтырылуын искәртте.

– Ел саен республикада 3 миллион квадрат метрдан артык торак салына. Шуларның күпчелеге шәхси йортларга туры килә. Бүген газлаштыруга ихтыяҗ зур. Республика халкыннан, газ тоташтыруны сорап, 18 мең гариза кергән. Шуның 16 меңе белән килешү төзелгән. 8 мең кешенең йортына газ килгән. Бу программа, зур эш белән беррәттән, күп акча да таләп итә. Республикада әлеге эшләр «Газпром» оешмасы ярдәме белән башкарыла. Бүгенге бүләк өчен аларга тагын бер кат рәхмәтләребезне җиткерик, – диде Президент.

Тантанага «Газпром» оешмасының департамент җитәкчесе Владимир Марков та килгән иде.

– Без Татарстанны 18,5 млрд кубометр газ белән тәэмин итәбез. Моны, республика халкы уңайлы шартларда яшәсен, дип эшлибез. Алга таба да бергәләп эшләргә язсын. Бүген без Әйшә авылы халкын гына түгел, республикада яшәүчеләрнең һәркайсын котлыйбыз. Зәңгәр ягулыклы булу – зур бәхет ул, – диде Мәскәү кунагы.

Инде алдан хәбәр итүебезчә, газлаштыру программасы ярдәме белән зәңгәр ягулык кешеләрнең капка төбенә кадәр килә. Моның өчен бер тиен дә түлисе түгел. «Газпроммежрегионгаз» оешмасының генераль директоры Сергей Густов та әнә шулай дип халыкны сөендерде.

– Татарстанда газны йорт эченә кадәр керткәндә, авыр хәлдә калучылар, төрле категория кешеләре өчен махсус субсидия дә булдырылды. Әлегә гариза бирүчеләр 18 мең булса, алга таба бу сан тагын да артыр дип көтелә. Йортлар төзелеп тора, ә газ кирәк. Бары өч документ – йортка хуҗа булу турында таныклык, СНИЛС һәм паспорт белән газлаштыру программасында катнашып була. Йортка кадәр китерелгән газ плитәдә дә, торбада да булачак. Мичкә ягасы түгел, электр белән җылытып, күп акча түләргә кирәкми, – диде ул.

Мичкә ягу дигәннән, Әйшә авылының Тихая урамында яшәүче Моратовлар 2015 елдан бирле йортларын утын белән җылыткан.

– Президент киләчәк, дигәч, бик борчылдык. Безнең йортыбызга кереп, газ тоташканны күреп чыгачак, дигәч, бөтенләй йокым качты. Гади генә кунак түгел бит! Бик дулкынланабыз, – ди Гөлсирин ханым.

Алар Әйшә авылына 1984 елда әти-әнисе белән күченеп килгәннәр. Ул чакта Гөлсирингә 6 яшь була. Ире Илшат та – шушы авылныкы. Алар 1998 елда гаилә корып җибәргәннәр. Ике бала үстерәләр. Уллары, өйләнеп, аерым яши, кызлары – мәктәп укучысы. Ике оныклары да бар икән. Җылы өйдә алар хәзер көтелгән кунак булачак. Ә йортларын 2015 елда ук төзеп бетергән булганнар.

– Көн дә утын яктык. Рәхәт нәрсә түгел. Өч сәгатьтән өч сәгатькә будильник куеп, йокыдан торып, мичкә утын өстәр идек. Аллага шөкер, каян килеп чыкты бу газлаштыру программасы?! Ишетүгә, урамыбыз белән гариза илттек. Өч ел элек газ казаны алып куйган идек. Анысы булгач, тоташтыру артык кыйммәткә чыкмады. Бик сөендек. Идәннәрнең җылылыгын күрегезче! Рәхмәт дими, ни диярсең?! Барлык җитәкчеләргә, газчыларга, район башлыгына чиксез рәхмәтлебез.

Әйшә авылының бүген газ килгән урамында иң беренче булып йортны Дьяченколар гаиләсе салып чыга. Авыл халкы исеменнән алар гаиләсе Президентка җылы сүзләр җиткерде.

– Безнең урамнарда яшь гаиләләр яши. Барыбызда да – кечкенә балалар. Бүген сөенечтән балкыйбыз. Тышта нинди генә һава торышы булса да, өйдә җылы булачак, – диде Светлана Дьяченко.

Ә менә Салават абый Кәлимуллин Әйшәгә 2 ел элек Түбән Камадан күченеп килгән. Сургут якларында яшәгән кеше ул. Барлык туганнары да Әйшәдән йорт алгач, ул да монда килергә уйлаган. «Йортым бик зур. Газ кергәнгә ышанып та булмый әле. Электр белән җылыту түгел инде ул. Рәхәткә чыктык», – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

# Өметле башлангыч

Кеше өчен дә, үсеш өчен дә кирәк. Кичә Яшел Үзән районында Свияжск төбәкара мультимодаль логистик үзәгенә баручы газүткәргечнең беренче җөен символик рәвештә эретеп ябыштыру чарасы булды. Республика өчен әһәмиятле проектка хәер-фатиха бирүчеләр арасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, «Газпром» җәмгыяте департаменты начальнигы Владимир Марков, «Газпром межрегионгаз» һәм «Газпром газификация» җәмгыяте генераль директоры Сергей Густов, «Газпром трансгаз Казан» җәмгыяте генераль директоры Рөстәм Усманов бар иде.

Искәртеп үтик: бу елның 12 октябрендә «Россия энергетика атнасы – 2022» халыкара форумы кысасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм «Газпром» җәмгыяте идарәсе рәисе Алексей Миллер 2025 ел азагына кадәр төбәкне газ белән тәэмин итү һәм газлаштыру үсеше программасын имзалады. Шунысын да әйтергә кирәк: республика белән җәмгыять арасында әлеге килешү беренче тапкыр төзелде. Шушы программа нигезендә Әгерҗе, Азнакай, Әлмәт, Әтнә, Югары Ослан һәм Яшел Үзән районнарында, шулай ук «Зур Яшел Үзән» проектының Казаннан көнбатышка таба территориясен газлаштыру каралган. Бу – 7,4 мең йорт һәм 13 котельныйга газ керәчәк дигән сүз.

Әлеге газүткәргеч 24 чакрымга сузылган һәм алдарак әйтеп үтелгән программаның республикадагы тәүге объекты булып санала.

Татарстан Президенты искәрткәнчә, Свияжск логистик үзәге республиканың икътисади үсеше өчен гаять мөһим. «Әлеге мәйданчыкта транспорт инфраструктурасы яхшы. Газ мәсьәләсе дә мөһим иде. Бүген яңа төзелешкә башлангыч бирдек», – диде Рөстәм Миңнеханов. Аның сүзләренчә, проектны чынга ашыру логистик үзәкнең үсеш мөмкинлекләрен тагын да арттырачак. Ул «Газпром» җәмгыяте җитәкчесенә шушы проектка алынулары өчен рәхмәтен дә җиткерде.

– Бүгенге чара – зур хезмәттәшлекнең башы. Татарстан белән булган мөнәсәбәтләребез әлеге проектны уңышлы тормышка ашыруга гына түгел, республиканың үсешенә дә ярдәм итәр дип ышанабыз, – диде чара барышында Владимир Марков.

# Яңартып агарту

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Интернетка тоташтыру кыенлыгы барлыгын Людмила Рыбакова да искәртте. «Миңа беркетелгән Чирмешән районында гына да 46 мәдәният оешмасының бары 2се генә интернет челтәренә тоташтырылган. Бу мәсьәләне китапханәләр дә күтәргән иде», – диде ул.

Интернет булмаган авыл клублары белән без дә элемтәгә кердек. Тукай районының Борды авылы клубы мөдире Нурия Рамазанова дөнья пәрәвезеннән башка бик кыен икәнлеген әйтте.

– Интернет булмау эшкә комачаулый. Әллә никадәр чара үткәрергә, шулар турында мәгълүмат җибәрергә кирәк. Электрон почта буенча хатларга җавап бирәсе бар. Бу эшләрне телефон аша эшләп булмый, – диде ул.

### Хисап туйдыра

Без укытучылар гына хисап эшеннән зарлана, дип уйлый идек, юк, алар гына түгел икән. Командировкаларда йөргәндә, клуб мөдирләреннән дә ишетәбез мондый зарны.

– Безгә бит ике көн саен чара уздырырга кирәк. Аларның хисабын, фотосын сорыйлар. Аны социаль челтәрләрдә таратырга кирәк. Көн саен авыл җирендә шуның кадәр кешене каян чакырып бетерәсең ди?! Бер килгәндә, берничә чараны үткәреп, фотоларга төшерәбез. Киемнәрне дә алыштырырга туры килә. Кыскасы, мая туплыйбыз. Аннан эшебезне күрсәтеп, социаль челтәргә куябыз. Берсендә бер бала, аптырап: «Апа, әйдә, берьюлы бер айга җитәрлек итеп төшереп куйыйк әле, һаман саен чыгасы булмас», – дип куйды. Сыйфат түгел, сан артыннан куабыз бит, – диде исемен күрсәтмәүне үтенгән клуб мөдире.

Дөрес, утырышта, клубларда хисап эшеннән зарланалар, дигән сүз булмады. Әмма Марат Әхмәтовның үткәрелгән чараларның күплегенә бераз шикләнеп куюын шуңа ишарә дип аңладык.

– 1900 мәдәни оешма, 9 меңгә якын хезмәткәр. Бу – бик зур коллектив. Чаралар республикадагы күпмилләтле халыкның мәнфәгатьләрен исәпкә алып оештырыла. Халыкара дәрәҗәдәге – 750 диплом, бөтенроссия күләмендә – 541, төбәк дәрәҗәсендә 578 диплом бар. Бу күрсәткечләр күпмедер дәрәҗәдә эшнең сыйфаты турында сөйли, дип әйтәм. Эшләре тыгыз, 331 меңнән артык чара үткәрелгән. Мин әле бераз шикләнеп тә калдым: елның һәр ике көнендә нинди чара уздырырга мөмкин? Бәлкем, киләчәктә саннар артыннан кумыйча, сыйфатка күбрәк игътибар итәргә кирәктер? Бу Мәдәният министрлыгына да, муниципаль оешмаларга да кагыла, – диде Марат Әхмәтов.

Аксубай районы мәдәният йорты җитәкчесе Ольга Копанева чыгышыннан да эш күләме зурлыгын чамаларга була иде. Райондагы үзәкләштерелгән клуб системасы 52 клубны берләштергән.

– Соңгы биш елда 20 грант (гомуми суммасы 5 миллион сумнан артык) оттык. Бу акчаның бер өлешенә тегү цехы ачып, сәхнә костюмнары тектердек. Артистлар өчен костюм бик зур әһәмияткә ия. Хәзер аны әзерләү чыгымы биш тапкыр кимеде. Барлыгы меңнән артык татар, рус, чуаш костюмнары тектердек, – диде Ольга Копанева.

Музыка яздыру студиясен дә яңартка累 каннар. Хәзер балалар коллективлары үз клипларын төшерә ала. Һөнәрчелек буенча остаханәләр булдырылган. Каникулда анда балалар да, яшьләр дә килә. «Пушкин картасы» ярдәмендә узган елның өч аенда гына 1 миллион 200 мең сумнан артык акча эшләгәннәр. Районда «Пушкин картасы»н иң күп кулланган кешегә Кыш бабай велосипед алып киләчәк.

«Пушкин карта»сы темасына утырышта Марат Әхмәтов та тукталды.

– Яңа мөмкинлекләрне һичшиксез эзләргә кирәк, заман шуңа таба бара. «Пушкин картасы» да – шуның бер мисалы. Ул республикада балалар арасында да әдәбият, мәдәният, сәнгатькә ихтыяҗ зурлыгын күрсәтә. «Пушкин картасы»н куллану күрсәткече буенча без Мәскәү өлкәсе, Санкт-Петербургтан соң торабыз икән, димәк, республикада бу хезмәткә ихтыяҗ зур, – диде ул.

Белмим, клуб хезмәткәрләре сөенерме – аларга кагылышлы яңалык бар. Мәдәният йорты хезмәткәрләре өчен җир кишәрлеге бүлеп бирү турында закон кабул ителгән. Аны алу өчен, яшь белгечләр, мәдәният йорты хезмәткәрләре исәпкә басарга тиеш.

Сәрия МИФТАХОВА

# Алар – һәркемгә үрнәк

**Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы өлкәсендәге алдынгы хезмәткәрләргә, иң яхшы медик, укытучы, иҗат, фән-техника, спорт өлкәсе вәкилләренә дәүләт бүләкләре тапшырды. Бүләкләү тантанасы Казан Кремлендә узды.**

«Бу залга төрле һөнәр вәкилләре: эшчеләр, авыл хезмәтчәннәре, дәүләт хезмәткәрләре, фән, мәдәният, медицина, мәгариф, физик культура һәм спорт өлкәсе эшлеклеләре җыелган, – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин, бүләкләнүчеләрне Президент, Дәүләт Советы депутатлары исеменнән сәламләп. – Сез – безнең горурлыгыбыз. Гомуми уңышыбыз нәкъ менә сезнең шәхси казанышларыгыздан туплана, республика тормышының елъязмасы языла. Сез намуслы хезмәтегез, республика язмышына битараф булмавыгыз белән үсеп килүче буынга һәм республикабызда яшәүчеләрнең барчасына лаеклы үрнәк күрсәтәсез». Фәрит Мөхәммәтшин тантананың Татарстан Конституциясенә 30 ел тулу уңаеннан узуын басым ясап әйтте.

Фәрит Мөхәммәтшин авыл хезмәтчәннәренә тырышлыклары өчен рәхмәт сүзләрен ирештереп, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме буенча Татарстанның Россия субъектлары арасында лидерлар сафында баруын искә төшерде. Республика авыл хуҗалыгы продукциясенең барлык төрләре белән үзен тулысынча тәэмин итә һәм әле читкә дә җибәрә. «Авылларның картаюына, яшьләр өлеше кимүенә карамастан шулай, – диде парламент башлыгы. – Азык-төлек муллыгы өчен авыл хуҗалыгының гаять зур әһәмияткә ия булуын, шулай ук халык традицияләрен, милли мәдәният һәм телне саклау зарурилыгын исәпкә алып, авылга ярдәм итүдә мөмкин булганның барысын да эшлибез».

Парламент башлыгы фикеренчә, барлык милләт һәм дин вәкилләренең бердәмлеге уңышлы үсештә мөһим роль уйный.

Дәүләт Советы Рәисе бүләкләнүчеләргә республиканың социаль-икътисади, мәдәни һәм рухи үсешенә лаеклы өлеш кертүләре өчен рәхмәт белдерде һәм саулык-сәламәтлек, уңышлар, озын гомер теләде.

Фәрит Мөхәммәтшин 40тан артыграк кешегә Россия һәм Татарстан дәүләт бүләкләрен тапшырды.

# 18 ноябрьгә билгеләнде

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының утыз җиденче утырышы 18 ноябрьдә узачак. Парламент Президиумы утырышында шундый карар кабул ителде. Депутатлар 15 мәсьәлә, шул исәптән 4 республика законы проектын һәм 3 федераль закон проектын карап тикшерүне күздә тота. Утырышның көн тәртибенә кертелгән республика законы проектларының икесе – беренче, тагын икесе икенче укылышта каралачак.

2023 елга һәм пландагы 2024, 2025 елларга Татарстан Республикасы бюджеты һәм Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында закон проектлары икенче укылышка әзерләнгән. Беренче укылышта мәгариф турында (физик мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр бушлай ашатуны күздә тоткан) һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары проектларының җайга салу көчен бәяләү турында республика законнарына үзгәрешләр кертү хакында закон проектлары каралачак.

Утыз җиденче утырышта шулай ук Дәүләт Советының калдыклар белән эш итү өлкәсендә федераль законны камилләштерү инициативасы каралачак. Аерым алганда, Дәүләт Советы җитештерү һәм куллану калдыклары турында федераль законга үзгәрешләр кертү хакында закон проектын Дәүләт Думасына кертүне, шулай ук Россия парламентының түбәнге палатасы Рәисе Вячеслав Володинга һәм Хөкүмәт Рәисе Михаил Мишустинга сыек көнкүреш калдыклары белән эш итүне хокукый җайга салу буенча тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итәргә ниятли.

«Коммуналь калдыкларны җыю, саклау, утильләштерүгә кагылышлы кайбер мәсьәләләр әлегәчә закон нигезендә җайга салынмаган, – диде Фәрит Мөхәммәтшин, әлеге мәсьәләгә тукталып. – Кайбер очракларда, аерым алганда, сыек көнкүреш калдыклары буенча, федераль дәрәҗәдә карарлар кабул итү таләп ителә. Сыек калдыкларның еш кына сулыкларга агызылуы сер түгел, ә бу безнең сәламәтлегебездә чагылыш таба».

Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина билгеләп үткәнчә, утыз җиденче утырыш кысасында Дәүләт Советының киләсе елга закон проектларын эшләү буенча үрнәк планы проекты каралачак. Көн тәртибенә шулай ук Дәүләт Советының Яшьләр парламенты турында карарына үзгәрешләр кертү хакында мәсьәлә урын алган. Депутатлар, федераль закон чыгаручылар кебек үк, яшьлек чорын 35 яшькә кадәр җиткерүне тәкъдим итә (Россиядә кабул ителгән яңалыкларны һәм киләсе чакырылышларда яшьләр парламентларын булдыруда исәпкә алу өчен).

Утырышта депутатлар Дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә комитетының алтынчы чакырылыш башланганнан бирле эше турында һәм Югары Суд Рәисенең Татарстанда җәмәгать юстициясе эшчәнлеге турында чыгышын тыңлаячак.

Президиум утырышында шулай ук Татарстан Президентының Дәүләт Советына Юлламасындагы тәкъдимнәрне тормышка ашыру буенча Дәүләт Советының чаралар планы каралды. Юлламадагы 29 тәкъдим буенча 60 төп чара планлаштырылган.

«Илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга, авыл хуҗалыгын үстерү һәм икътисади бурычларны хәл кылу, икътисадны квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү, халыкны социаль яклауга зур игътибар биреләчәк», – дип сөйләп үтте Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Юрий Камалтынов.

Планда яшьләрдә ватанпәрвәрлек рухын, җаваплылык хисен тәрбияләү мәсьәләсе аерым игътибар үзәгенә алынган. Юрий Камалтынов Дәүләт Советының бу җәһәттән тиешле закон проектын әзерләячәген искәртте.

Президиум утырышында башка мәсьәләләр дә каралды.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ КАРАРЫ

**гражданка Р.Г. Ниязова шикаятенә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре, 2022 елның 18 октябре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка Р.Г. Ниязова шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Э.М. Мостафина мәгълүматын, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең конституциячел законнар бүлеге мөдире Л.И. Ибраһимова, Татарстан Республикасы Конституция суды инициативасы буенча суд утырышына чакырылган белгечләр – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты юридик бүлеге башлыгы урынбасары Е.В. Кожевникова, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты бюджет башкарылышы бүлеге башлыгы Л.В. Вәлиева аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле – Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы урынбасары И.А. Гомзик, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсе башлыгы М.Б. Сөнгатуллин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Хокук идарәсенең административ хокук һәм законнарны системалаштыру бүлекчәсе мөдире К.А. Align Изнова, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле – Татарстан Республикасы Югары суды судьясы С.А. Трошин, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле – Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге башлыгы Р.Р. Шкаликов, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле – Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.А. Зорькина, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы Е.Ю. Степанова чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Р.Г. Ниязова «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук – Татарстан Республикасы Законы) 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы юридик зат хокукына ия, аның Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте төшерелгән һәм үз исеме язылган мөһере, шулай ук тиешле бюджет счетлары һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә ачыла торган башка счетлары бар.

Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Президенты җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасына түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты);

2) Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең республика агентлыклары, хезмәтләре, инспекцияләре, үзәкләре, палаталары, департаментлары, комитетлары, баш идарәләре, идарәләре, комиссияләре һәм башка органнары (Татарстан Республикасы ведомстволары);

4) Татарстан Республикасы вәкилләкләре.

Татарстан Республикасы Законының 30 статьясы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты юридик зат булып торуын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты расләый торган Нигезләмә нигезендә эш итүен; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратын тоту чыгымнарын финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын тоту чыгымнары чикләрендә гамәлгә ашырылуын (3 һәм 4 пунктлар) күздә тота.

Татарстан Республикасы Законының китерелгән нигезләмәләренә таянып, гражданка Р.Г. Ниязова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты кебек үк, юридик зат хокукларына ия дип саный.

Мөрәҗәгатьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар кучермәләреннән аңлашылганча, Татарстан Республикасы Югары суды билгеләмәсе белән мөрәҗәгать итүче файдасына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан 15 300 сум күләмендә суд чыгымнарын түләтү билгеләнгән. Әлеге суд акты нигезендә гражданка Р.Г. Ниязова Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына тапшырган үтәтү кәгазе бирелгән. Шул ук вакытта үтәтү кәгазе, үтәлмичә, мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган, чөнки бурычлының күрсәтелгән Департаментта һәм аның территориаль бүлекләрендә ачылган шәхси счетлары юк.

Гражданка Р.Г. Ниязова фикеренчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының шәхси счетлары булмау әлеге оешманың юридик зат буларак теркәлмәвенә бәйле. Мөрәҗәгать итүче санаганча, бу үзе шикаять белдерә торган Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре хокук куллану практикасында, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма һәм күрсәтмә бирү органы буларак, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының юридик зат итеп теркәлмәгән булырга мөмкинлек биргән дәрәҗәдә әлеге нормаларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы мәсьәләдә билгесезлек тудыра. Татарстан Республикасы Законының дәгъва белдерелә торган нигезләмәләрен кулланунның мондый практикасы, гражданка Р.Г. Ниязова фикеренчә, суд карарын үтәүгә аның конституциячел хокукын гамәлгә ашыруга каршы килә.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенең 18, 19, 24 (беренче һәм икенче өлешләр), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 40 (беренче өлеш), 41, 60, 103 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә Татарстан Республикасында хосусый, дәүләти, муниципаль милек һәм милекнең башка рәвешләре бертигез дәрәҗәдә таныла һәм яклана; җир һәм башка табигать ресурслары хосусый, дәүләти, муниципаль милектә һәм милекнең башка рәвешләрендә булырга мөмкин; милек кагылгысыз; законлы рәвештә булдырган мөлкәтне биләргә, аннан файдаланырга, аның белән эш итәргә милекченең хокуклары чикләү, федераль законда каралган очраклардан гайре, рөхсәт ителми; милек дәүләт һәм җәмгать мәнфәгатьләренә, кеше хокукларына, ирекләренә һәм абруена каршы кулланылмаска тиеш; милек объектларын ирексезләп тартып алу, федераль законда билгеләнгән очраклардан гайре, рөхсәт ителми; Татарстан Республикасы Конституциясе – республиканың Төп законы, Татарстан Республикасының хокукый системасында иң югары юридик көчкә ия, турыдан-туры гамәлдә була һәм Татарстан Республикасының барлык территориясендә кулланыла; Татарстан Республикасы законнары һәм башка хокукый актлары, шулай ук җирле үзидарә органнарының хокукый актлары Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килмәскә тиеш; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмгать берләшмәләре, оешмалар, учреждениеләр, вазыйфаи затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм гражданнар хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль һәм мөлкәти хәленә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; Татарстан Республикасында һәркемгә аның хокуклары һәм ирекләрен, намусын һәм абруен, гомерен, сәламәтлеген һәм мөлкәтен суд тарафыннан яклау тәэмин ителә; дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, вазыйфаи затларның, шулай ук җәмгать берләшмәләренең карарларына һәм гамәлләренә (яисә гамәл кылмавына) карата судка шикаять бирелергә мөмкин; Татарстан Республикасында һәркем Татарстан Республикасы Конституциясен һәм Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясе Конституциясен һәм федераль законнарны үтәргә тиеш; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара һәм аларның үтәлешен тикшерә; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләрен Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәү мәҗбүри.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре аларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының да һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының да хокукый нигезләмәсен билгеләүне җайга салу аңа, хокук куллану практикасы бирә торган мәгънәсеннән чыгып, гражданнның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан суд чыгымнарын түләтү турында суд актын үтәү хокукын гамәлгә ашыруга каршы килгән һәм шуның белән аның суд яклавына хокукын чикләгән дәрәҗәдә әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нормалар дәүләт хакимияте органнары системасын оештыру мәсьәләләренә карый. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешенең «н» пункты) нигезендә дәүләт хакимияте органнары системасын оештыруның гомуми принципларын билгеләү Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагына керә. Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, 2 һәм 5 өлешләре). Шул ук вакытта дәүләт хакимияте органнары системасы Россия Федерациясенең конституциячел төзелеш нигезләре һәм дәүләт хакимиятенең вәкиллекле һәм башкарма органнары оештыруның федераль законда билгеләнгән гомуми принциплары нигезендә Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә (Россия Федерациясе Конституциясенең 77 статьясы, 1 өлеш).

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон преамбуласының беренче абзацы нигезендә (алга таба шулай ук – 184-ФЗ номерлы Федераль закон) Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары системасы алар тарафыннан Россия Федерациясенең конституциячел корылышы нигезләре һәм әлеге Федераль закон нигезендә мөстәкыйль билгеләнә.

184-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 3 өлеше нигезендә (2022 елның 1 июненә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы исеме, аның структурасы, аны формалаштыру тәртибе Россия Федерациясе субъектының тарихи, милли һәм башка традицияләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе субъекты Конституциясе (уставы) һәм законнары белән билгеләнә.

Шуның белән, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын кабул итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Россия Федерациясе Конституциясендә билгеләнгән Россия Федерациясе һәм аның субъектлары карамагындагы мәсьәләләрне бүлешүдән чыгып эш иткән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 13 пункты нигезендә үзенә бирелгән вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, аның нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары системасын билгеләү Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына керә.

3. 184-ФЗ номерлы Федераль законның (2022 елның 1 июненә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) 17 статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъектында Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчелегендә башкарма хакимият органнары системасы билгеләнә (1 пункт); Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы Россия Федерациясе субъекты конституциясе (уставы) нигезендә Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесе) тарафыннан билгеләнә (4 пункт).

Татарстан Республикасы Конституциясенең 9 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары системасын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнары тәшкил итә (өченче өлеш).

Күрсәтелгән хокукый җайга салуның дәвамы буларак, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарын төзүгә һәм аларның эшчәнлегенә бәйле хокук мөнәсәбәтләрен регламентлаштыру максатларында карала торган Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән. Шулай, әлеге Татарстан Республикасы Законының шикаять белдерелә торган 8 статьясы белән республика закон чыгаручысы Татарстан Республикасы Президенты җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасына түбәндәгеләр керә дип билгеләгән:

1) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

2) Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең республика агентлыклары, хезмәтләре, инспекцияләре, үзәкләре, палаталары, департаментлары, комитетлары, баш идарәләре, идарәләре, комиссияләре һәм башка органнары (Татарстан Республикасы ведомстволары);

4) Татарстан Республикасы вәкилләкләре.

Китерелгән норма үзенең хокукый мәгънәсе буенча Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләренә охшаш, аларны конкретлаштыруга һәм закон акты дәрәҗәсендә структуралаштыруга юнәлдерелгән, һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми.

Югарыда аталган системага керүче башкарма хакимият органнары статусы Татарстан Республикасы Законының дәгъва белдерелә торган 6 статьясы белән билгеләнә, аның нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы юридик зат хокукына ия, аның Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте төшерелгән һәм үз исеме язылган мөһере, шулай ук тиешле бюджет счетлары һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә ачыла торган башка счетлары бар (1 пункт).

Күрсәтелгән норманың хокукый эчтәлеге 184-ФЗ номерлы Федераль законның (2022 елның 1 июненә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) 20 статьясындагы 4 пункты нигезләмәләреннән турыдан-туры килеп чыккан, алар нигезендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы юридик зат хокукларына ия, герблы мөһере бар. Шуның белән бергә «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә бүгенге көндә әлеге норма үз көчен югалткан дип танылуын да билгеләп үтәргә кирәк. Әмма бу Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте башкарма органнарының юридик зат хокукларын һәм гербле мөһере булу мөмкинлеген кире какмый.

Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктының 3 пунктчасының һәм 10 статьясындагы 3 пунктының нигезләмәләре нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – үзенең ведомство территориясе чикләрендә үз карамагындагы мәсьәләләр буенча дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы, үзенә буйсынган, тармакара һәм махсус компетенциядәге башкарма хакимият органнарын берләштерүче һәм аларның эшчәнлеген юнәлеш бирүче башкарма хакимиятнең гомуми компетенциядәге даими эшләүче коллегиаль органы.

Карала торган Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пункты нигезләмәләре белән үзара бәйләнештә күрсәтелгән нормаларның эчтәлегеннән һәм хокукый мәгънәсеннән күренгәнчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – юридик зат хокукларына ия булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма һәм күрсәтмә бирү органы. Аталган башкарма хакимият органының юридик зат хокуклары булу аның оештыру һәм функциональ бәйсезлеге гарантияләрен берсе булып тора, чөнки гамәлдәге законнар нигезендә мондый статус аңа йөкләнгән функцияләрне аннан башка нәтиҗәле гамәлгә ашырып булмый торган мәҗбүри шарт булып тора. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең төп эшчәнлеген гомумдәүләт, региональ мәсьәләләрне хәл итү өчен гавами хокук кысаларында гамәлгә ашыра һәм шул максатларда гражданлык мөнәсәбәтләре әйләнешенә керә, бу аның хокукый сәләтенең катлаулы составтагы характеры турында сөйли. Күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук Россия Федерациясе Граждан кодексының 124 һәм 125 статьялары белән үзара бәйләнешендә әлеге кодексның 2 статьясындагы 1 пунктының 2 абзацындагы нигезләмәләргә дә туры килә, алар нигезендә Россия Федерациясе субъектлары, дәүләт хакимияте органнары исеменнән, граждан законнары белән җайга салынучы мөнәсәбәтләрдә шул мөнәсәбәтләрдәге башка катнашучылар – гражданнар һәм юридик затлар белән бер үк нигезләрдә эш йөртәләр; шул ук вакытта аларга, әгәр законнан яисә бу субъектларның үзенчәлегеннән башкасы килеп чыкмаса, граждан законнары белән җайга салынучы мөнәсәбәтләрдә юридик затларның катнашуын билгели торган нормалар кулланыла.

Россия Федерациясе Конституция Суды үз карарларында күрсәткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясе мәгънәсе буенча (34 статья, 1 өлеш) бер үк зат дәүләт идарәсе өлкәсендәге хакимият эшчәнлеген һәм системалы табыш алуга юнәлдерелгән эшмәкәрлек эшчәнлеген берләштерә алмый; федераль закон чыгаручы дәүләт хакимияте дәрәҗәләре арасында вәкаләтләрне бүлешеп кенә калмый, ә тиешле вәкаләтләргә карата Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының субъектлык хокуклары үзенчәлекләрен дә билгели, алар хакимияткә буйсынуга нигезләнгән мөнәсәбәтләрдә дәүләт атрибутикасына ия булучы хакимият ияләре сыйфатында булалар, ә граждан-хокукый мөнәсәбәтләрдә бу мөнәсәбәтләрнең башка катнашучылары белән бертигез булалар; шул ук вакытта, Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары граждан-хокукый мөнәсәбәтләрдә махсус хокукый сәләте булган субъектлар буларак катнашалар, ул аларның гавами-хокукый табигате нигезендә граждан хокукының башка субъектларыннан – гражданнарның һәм юридик затларның хокукый сәләтенә туры килми (1998 елның 1 октябрендәге 168-О номерлы; 2006 елның 2 ноябрендәге 540-О номерлы билгеләмәләр).

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты махсус хокукый сәләткә ия, ул үзенең гавами-хокукый табигате нигезендә граждан хокукының башка субъектлары – гражданнарның һәм юридик затларның шәхси мәнфәгатьләрне күздә тоткан хокукый сәләте белән туры килми дигән нәтиҗәгә килә. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан куелган мәсьәләгә карата бу федераль һәм республика законнары нигезендә юридик зат хокукларына ия булган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак теркәү узарга тиеш түгел дигәнне аңлата.

Шул ук вакытта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының китерелгән эш режимы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеген тәэмин итү һәм ул кабул иткән карарларның башкарма хакимият органнары тарафыннан башкарылуын тикшереп торуны оештыру максатларында төзелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының төзелүен алдан билгеләгән, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын тоту чыгымнары чикләрендә Татарстан Республикасы Законының шикаять белдерелә торган 30 статьясындагы 4 пункты нигезендә финанслана һәм Татарстан Республикасы Законының шушы ук статьясының дәгъвалана торган 3 пункты нигезендә аңа юридик зат статусы бирелгән. Карала торган Татарстан Республикасы Законының аталган статьясы белән аларның үзара бәйләнешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 5 декабрендәге 563 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты турындагы нигезләмә нормаларының эчтәлегеннән күренгәнчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеген оештыру, хокукый, мәгълүмати, матди-техник һәм финанс ягыннан тәэмин итү мәсьәләләрен аның Аппараты тарафыннан тәэмин ителә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының китерелгән вәкаләтләре характеры аның граждан законнары белән җайга салынучы мөнәсәбәтләрдә катнашу үзенчәлекләренә тәэсир итә, шулай ук юридик зат буларак граждан-хокукый хокукый сәләткә ия булу һәм теркәлү кирәклеген дә бәйле.

Мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан суд чыгымнарын түләтү турында үз файдасына чыгарылган суд актын үтәтеп булмау турындагы дәлилләренә карата Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк дип саный.

Россия Федерациясе Конституция Суды бернichә тапкыр күрсәткәнчә, суд яклавына хокукын тулы күләмдә тормышка ашырырга һәм тигезлек, гаделлек таләпләренә җавап бирүче гадел хөкем аша хокукларны нәтиҗәле торгызуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирүче гарантияләр булуны күздә тота; шул исәптән дәүләт органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән хокук бозуларны да кертеп, шул ук вакытта теләсә нинди хокук бозуларны бетерүнең кирәкле хокукый механизмнарын булдырып, дәүләт хокукларны һәм ирекләрне танырга, үтәргә һәм якларга тиеш (2011 елның 22 апрелендәге 5-П номерлы, 2012 елның 27 декабрендәге 34-П номерлы, 2013 елның 22 апрелендәге 8-П номерлы, 2015 елның 31 мартындагы 6-П номерлы һ.б. карарлар).

«Россия Федерациясендә суд системасы турында» 1996 елның 31 декабрендәге 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел законның 6 статьясындагы 1 өлеше нигезләмәләре буенча федераль судларның, җәмгать судьяларының һәм Россия Федерациясе субъектлары судларының законлы көченә кергән карарлары, шулай ук аларның башка күрсәтмәләре, таләпләре, йөкләмәләре, чакырулары һәм башка мөрәҗәгатьләре дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, җәмгать берләшмәләренең, вазыйфаи затларның, башка физик һәм юридик затларның берниндидә искәрмәсез барысы өчен дә мәҗбүри булып тора һәм Россия Федерациясенең бөтен территориясендә тайпылышсыз үтәлергә тиеш.

Китерелгән җайга салу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 5 декабрендәге 563 номерлы карары белән расланган Татарстан Респуб-

ликасы Министрлар Кабинеты регламентының (алга таба шулай ук – Регламент) 106 статьясындагы икенче абзацы нигезләмәләрендә үз чагылышын тапкан, алар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына куелган таләпләр суд тарафыннан канәгатьләндерелгән очракта, тиешле башкарма хакимият органы билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән карар турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кичекмәстән хәбәр итә, суд карарына карата шикаять бирү турында тәкъдимнәр кертә, ә суд карары үз көченә кергәч, аны үтәү чаралары турында белдерә.

Шуның белән бергә, хокук куллану практикасында дәгъва белдерелә торган нормаларның нигезләмәләрен бюджет законнары нигезләмәләре белән үзара бәйләнештә аңлату, шул исәптән Р.Г. Ниязова эше буенча хокук куллану карарларыннан күренгәнчә, юридик зат буларак теркәлү булмау һәм, нәтиҗәдә, аның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында шәхси счеты булмау сәбәпле, фактта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан суд чыгымнарын түләтү турында суд актларын үтәүнең мөмкин булмавына китерә. Шул ук вакытта, юридик зат статусы һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында тиешле тәртиптә ачылган шәхси счетлар булуга карамастан, аңа үтәтү кәгазе тапшыру да мөмкин түгел, чөнки бер ягы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты булган суд эшләрендә аның үзе урынына Аппаратын танырга ярамый, чөнки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасында дәүләт башкарма хакимиятенең гәүдәләнеше булып тора.

Күрсәтелгәннәр гражданны суд карарын үтәтү тәртибен үзгәртү турындагы таләп белән мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр итә. Күрсәтелгән хокук конституциячел гарантия булып торганда, мондый таләп суд яклавына хокукны иллюзор характерда итә, Россия Федерациясе Конституциясенең 46 статьясында (1 өлеш) беркетелгәнчә, һәр кеше, кирәк булганда, суд яклавына хокукыннан тулы күләмдә файдалана алсын өчен дәүләт кирәкле шартлар тудырырга тиеш.

Суд карарын үтәүнең мәҗбүри булуы нигезле рәвештә шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: гавами хакимият органын юридик зат буларак теркәүнең булмавы үзе үк гражданның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан суд чыгымнарын түләтү турында суд актын үтәтү хокукын гамәлгә ашыруга каршы килмәскә һәм шуның белән суд яклавына хокукка каршы төшмәскә тиеш. Киресенчә, федераль законнарның һәм Регламентның югарыда китерелгән нигезләмәләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм (яки) башкарма хакимиятнең алар тарафыннан вәкаләтләр бирелгән органы тиешле суд карарын үтәү буенча үзенә бәйле барлык чараларны күрергә тиеш, шул чакта шәхес, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрен үзара килештерү нигезендә гражданга бирелә торган акчаны тиешле срокта алу өчен реаль мөмкинлек тудырылыр иде.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2021 елның 26 апрелендәге 284 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан күчемсез мөлкәт объектларының кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләрен дәгъвалау турында административ эшләр буенча суд чыгымнарын түләтү турындагы суд актларында булган таләпләрне үтәү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы итеп билгеләгән. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары эшчәнлеген (төп функцияләрен) хокукый җайга салуда мондый якын килү Регламентның 106 статьясы күрсәтмәләре белән туры килер иде, суд карарларын үтәүнең мәҗбүрилеге турында югарыда күрсәтелгән Федераль конституциячел закон нигезләмәләренең тайпылышсыз үтәлешен тулысынча тәэмин итәр иде, шулай ук суд яклавының тулылыгы, нәтиҗәлелеге һәм үз вакытында башкарылуы конституциячел әһәмиятле максатларына ирешүгә ярдәм итәр иде дип саный.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре үзләре үк Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хокукый халәтен билгеләүгә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына юридик зат статусын беркетүгә юнәлдерелгән. Шул ук вакытта, гамәлдәге хокукый җайга салу системасындагы үз эчтәлегеннән, хокукый мәгънәсеннән һәм урыныннан чыгып, күрсәтелгән закон нигезләмәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан суд чыгымнарын түләтү турында суд актын үтәүгә гражданның хокукын гамәлгә ашыруга йогынты ясамый, чөнки дәүләт хакимияте органы тарафыннан мондый суд карарын үтәү мәҗбүрилеге аны юридик зат буларак теркәүгә бәйле түгел. Димәк, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре Татарстан Республикасы Конституциясенә, шул исәптән аның 28 (беренче һәм икенче өлешләр) һәм 40 (беренче өлеш) статьяларына туры килә.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 һәм 104 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга, чөнки алар үзеннән-үзе Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хокукый халәтен билгеләүгә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына юридик зат статусын беркетүгә юнәлдерелгән һәм аны юридик зат буларак теркәү фактына карамастан гражданның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан суд чыгымнарын түләтү турында суд актын үтәтү хокукын гамәлгә ашыруга каршы килмиләр, димәк, гражданның суд яклавына хокукын чикләмиләр.
2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.
3. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 108-П** **Татарстан Республикасы Конституция суды**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышын 2022 елның 18 ноябрендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 11 ноябре. № 1675-VI ДС

## Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 344-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
3. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 345-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
4. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 350-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 349-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. 2023 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы проекты турында.
7. «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буена Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
8. Сыек көнкүреш калдыклары белән эш итүне хокукый җайга салуны камилләштерү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында.
9. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында» 2019 елның 11 июлендәге 2983-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.
10. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетының 2019 елның сентябреннән 2022 елның ноябренә кадәрге эш чорына хисабы.
11. Татарстан Республикасында җәмәгать юстициясе эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисе мәгълүматы.
12. «Корал турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1196104-7 номерлы федераль закон проекты турында.
13. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 197803-8 номерлы федераль закон проекты турында (авыр үтелә торган җирлек, су, тау объектлары, спелеологик һәм башка объектлар буенча уза торган, тормыш өчен аеруча куркыныч тудыруга, туристларның (экскурсантларның) сәламәтлегенә һәм аларның мөлкәтенә зыян салуга бәйле булган хәрәкәт итү маршрутлары буенча мәгълүмат бирү тәртибен бозган өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).
14. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законның 126 һәм 134 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 212656-8 номерлы федераль закон проекты турында (бурычлының чираттан тыш каплана торган чыгымнары өлешендә).
15. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елы кысаларында чараларны гамәлгә ашыру турында».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 11 ноябре
№ 1676-VI ДС

# КОТЛЫЙБЫЗ!

«АГРОКӨЧ» акционерлык җәмгыятенең үсемлекчелек бүлеге әйдәүче агрономы **Әхмәтшин** Ренат Хәмзә улына, «Һадиев Данил Мөнип улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы баш агрономы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Сафиуллин** Газиз Вагыйзь улына **«Татарстан Республикасының атказанган агрономы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«ЧАЛЛЫ» клиника-санаторие җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең дәвалау-диагностика бүлекчәсе табиб-стоматологы **Беляева** Гүзәл Гамир кызына, «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең гинекология бүлекчәсе мөдире – табибы – акушер-гинекологы **Вәлиуллина** Миләүшә Разин кызына, «Авиамедсервис» ябык акционерлык җәмгыяте табиблык-очучылык эксперт комиссиясе рәисе **Гыймадиева** Гөлнар Шәфикъ кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор Е.В. Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 1 номерлы микрохирургия бүлекчәсе табиб-офтальмологы **Дмитриева** Татьяна Николаевнага, «Актаныш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Пучы участок хастаханәсе участок табиб-терапевты **Закиров** Ильяс Рафак улына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының академик В.М. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының эпидемиология мәсьәләләре буенча урынбасары **Максутова** Альбина Мәхмүт кызына, Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 3 номерлы хатын-кызлар консультациясе табибы – акушер-гинекологы **Сафиуллина** Наилә Фәрат кызына, «Авиатөзелеш районының консультация-диагностика үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте ортопедия бүлекчәсе мөдире – табибы – стоматолог-ортопеды **Хәбибуллин** Мәхмүт Нурулла улына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Сәламәтлек саклау тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең гомумхастаханә персоналы баш белгече – табиб-неврологы **Богданов** Әнвәр Ибраһим улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының икътисади һәм сәнәгать потенциалын үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «ТАИФ» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Шиһабетдинов** Альберт Кашаф улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

Терлекчелек

# СӨТЛЕ РӘХМӘТ

## ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕНИН ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗЫНДА ҺӘР СЫЕРДАН 32 КИЛОГРАММ СӨТ САВАЛАР

**Республика хуҗалыкларындагы табышның 79 проценты терлекчелек тармагыннан керә. Сөт сатудан алынган керем узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда 122 процентка арткан. Әмма тынычланырга иртәрәк әле: соңгы айларда 43 районның егермесендә сөт җитештерү төрле сәбәпләр белән кими. Ел дәвамында нибары 17 районда гына мөгезле эре терлекнең баш санын арттыра алганнар.**

Түбән тәгәрәүчеләр арасында кайчандыр терлекчелек тармагында әйдәп барган «Кызыл Шәрык Агро» хуҗалыклары да бар. Малларның баш санын киметеп, продукция алуны арттырып булмый шул. Чистай районы «Чистай Агро» җәмгыятендә дә кыска гына вакыт эчендә хуҗалыкның төп керем чыганагы булган сөт җитештерүдән бөтенләй баш тартып, 3700 баш сыерны юкка чыгарганнар.

Бер сыердан алынган сөт күләме 4–9 килограммнан артмаганда, терлекчелекнең файдасына караганда зыяны күбрәк бугай. Бүген Әлки, Югары Ослан, Апас, Чистай һәм кайбер башка районнарның 24 хуҗалыгында сөт җитештерү көннән-көн кими. Сөтең булмаса, кеременң аз. Хезмәт хакларын вакытында түләп бару да проблемага әйләнә. Авыл хуҗалыгы министрлыгы белгечләре әйтүенчә, 13 мең баш мөгезле эре терлеге булган «Ак Барс холдинг» хуҗалыкларында сөт җитештерүнең кимүе 700 миллион сумнан артык керем югалтуга китергән.

Терлекчелектәге аяныч хәлләрнең сәбәпләре нәрсәдә? Мондый хәлдән чыгу юллары бармы? Әлеге сорауга җавапны сөтчелек тармагында әйдәп баручы төбәк – Әтнә районының Ленин исемендәге колхозы мисалында эзләп карыйк. Колхоз системасын тулысынча диярлек саклап калган әлеге хуҗалык, һәр сыердан 32 килограмм сөт савып, көн саен 45 тонна югары сыйфатлы продукция җитештереп сата. Бер хуҗалык берничә район кадәр сөт җитештерә!

– Хуҗалыкта эшли башлаган вакытларны хәзер куркыныч төш шикелле искә алам. Югыйсә начар исәптә дә түгел идек кебек. Терлекчеләребез дә – булдыклы, уңган кешеләр. Иртә таңнан кичке караңгыга кадәр эшлибез. Ә нәтиҗә – бер сыердан уртача 5,6 килограмм! Шуны саткан акчага хезмәт хакы да түлибез, хуҗалыкның күп төрле хаҗәтенә дә тотабыз. Ашатырга печән, силос, сенаж, фураж да җитәрлек. Әллә кайларга барып, чөгендер калдыгы да алып кайтабыз. Ә сөт бик аз. Нишләргә? – дип искә ала ул вакытларны хуҗалык җитәкчесе Илгиз Хәйруллин.

Аның сүзләренчә, шундый көннәрнең берсендә районда терлекчелек буенча республика семинары узган. Төп соравына җавапны да шуннан алып кайткан җитәкче:

– Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты галиме Шамил ага Шакиров чыгышы хәтердә. Хикмәт ашатуда гына түгел икән. Савым сыерларын бозау чагыннан ук тәрбияли башларга кирәк. Азыкның сыйфаты, төрле катнашмалар, премикс һәм дистәләгән башка файдалы матдәләр белән дөрес итеп тукландырганда гына күп сөт алып була, ди профессор. Икенче атнада ук мин галимне үзебезнең хуҗалыкка чакырдым. Барлык белгечләр, терлекчеләр белән өч сәгатьтән артык сөйләштек. Шуннан башланды. Ул елларда сыерларга башлыча он тегермәненнән чыгарылган арыш һәм арпа катнашмасы бирә идек. Терлек азыгының сыйфаты да шулкадәр генә. Иң беренче эш итеп, азык әзерләү цехы булдырдык. Алты төрле катнашманы, тактадан махсус савытлар ясап, әчетеп ашата башладык. Сыер бит ул – бик рәхмәтле хайван. Үзенә игътибар артты исә, шунда ук сөтне күбрәк бирә башлый.

Хуҗалык җитәкчесе сүзләренә караганда, Шамил ага Әтнә районы белән генә түгел, сөтчелек тармагында республиканың барлык алдынгы хуҗалыклары белән дә даими бәйләнештә, берсенең эш тәҗрибәсен икенчеләргә җиткерергә тырыша. Кукмара районының «Вахитов» һәм «Урал» хуҗалыклары белән дә озак еллар хезмәттәшлек итә икән.

– Яшермим, әледән-әле илнең иң алдынгы хуҗалыкларында булырга туры килгәнгә, үземне сөтчелек тармагында шактый мәгълүматлы итеп тойган чакларым булгалады. Әмма Шамил ага белән сөйләшү-киңәшү дәвамында аның терлекчелек тармагында һәр яңалыктан хәбәрдар икәнлегенә сокланам. Тикмәгә генә аны «остазларның остазы» дип йөртмиләрдер шул инде, – ди Илгиз Хәйруллин.

Инде җиденче дистәсен түгәрәкләсә дә, Шамил Шакировны атна саен диярлек республиканың кайсы да булса хуҗалыгында очратып була, диләр. Кырык елдан артык терлекчелек тармагында хезмәт куйган фән эшлеклесе, республиканың иң алдынгы хуҗалыкларының эш тәҗрибәсенә таянып, 24 фән кандидаты, 2 фән докторы әзерләгән галим ул. Россия һәм Татарстан матбугатында 500дән артык фәнни хезмәте дөнья күргән, 17 китабы басылып чыккан.

Үземә дә аның белән Ленин исемендәге колхозның терлекчелек комплексында күрешергә насыйп булды. Хәйран калып карап йөрдем. Комплекста һәрбер эш роботлар ярдәмендә башкарыла! Роботларның сыер сауганын күргәнем бар иде. Монда исә 800 савым сыеры урнашкан зур бинада ярты сәгать саен роботларның маллар астын ялт иттереп чистартып чыгаруын күзәтү – үзе бер тамаша. Барлык эшләр дә заманча махсус җайланмалар ярдәмендә башкарыла.

– Күп сөт алырга теләсәң, малларны программа нигезендә дөрес итеп тукландыру кирәк. Моның өчен хуҗалыкка ай саен ким дигәндә 1 миллион сумлык төрле премикслар сатып алырга туры килә. Азык әзерләү үзәгендә бер сыердан 34 килограмм сөт саву мөмкинлегенә көйләнгән махсус программа нигезендә егермедән артык төр азык катнашмасы әзерләнә. Иң мөһиме – күп сөт алу сыерның сәламәтлегенә зыян китерергә тиеш түгел, – ди Шамил Шакиров.

Камил СӘГЪДӘТШИН

# ЧЫН БЕЗНЕҢЧӘ МАТУР, МОҢЛЫ КӨЙ...

## «ТАТНЕФТЬ» ОЕШМАСЫ ЯРДӘМЕ БЕЛӘН ТӨРКИ МУЗЫКАЛЬ МИРАСЫБЫЗГА ЯҢА СУЛЫШ ӨРЕЛДЕ

**Башкаладагы Милли китапханәнең тамаша залы сәхнәсендә сызылып кына кыл-кубыз тавышы ишетелә. Шунда ук аңа, акрынлап, думбра, дәф, курай тавышы да кушыла. Алар барысы да, бербөтен булып, үзебезчә матур, моңлы көй суза... Шушы көй сине әллә кая үткәннәргә, нәсел башында торган әби-бабаларыбыз яшәгән чорга алып кайта да алар белән бер сулышта яшәтә, бергә шатланырга, бергә сызланырга этәрә... «Almet Music Lab» музыкаль лабораториясендә иҗат ителгән альбомны тәкъдим итү кичәсендә тамашачы кичергән хис-кичерешләр бу.**

Милли җанлы бер төркем егет-кыз фәкать төрки уен коралларында гына уйнап язылган, борынгы көйләребездән торган альбом иҗат иткән. Проектның продюсеры, «Yummy Music» төркеме җитәкчесе Ильяс Гафаров сүзләренә караганда, альбомның тарихы моннан бер ел элек башланган. Төркем егетләре Әлмәттә эшләп килүче Дөнья халыкларының милли уен кораллары музее белән танышканнан соң бик илһамланып кайткан. Бер төркем музыкантны шушында бер атна яшәтеп, төрки уен коралларында көйләр иҗат итәргә иде, дип хыяллана алар. Хыялның чынга ашуын исә озак көтәргә туры килми. Егетләрнең бу тәкъдимен «Татнефть» оешмасы күтәреп алган.

«Әлмәт» иҗтимагый үзәгендә эшләп килүче әлеге үзенчәлекле музей да нефтьчеләр ярдәме белән ачылган булган. Бүген биредә 600дән артык уен коралы исәпләнә. Шуларның 116сы төрки халыкларныкы санала. Дөнья күләмендәге иң зур, уникаль төрки уен кораллары коллекциясе бу. Шуларның берсен – тюнгур дигән музыка уен коралын музейга «Татнефть» оешмасының генераль директоры Наил Мәганов шәхсән үзе бүләк иткән. Алтай һәм Якутия халкында киң таралган шаман барабанының бер төре бу. Гомумән, Наил Мәганов бу юнәлешкә зур игътибар бирә. Ул төрки уен коралларын халыкка танытуга зур өлеш керткән «Кадыйм Әлмәт» ансамбле концертларына да даими йөри. «Әлмәт» иҗтимагый үзәгендә, Дөнья халыкларының милли уен кораллары музеенда оештырылган чараларның берсен дә калдырмаска тырыша.

«Almet Music Lab» музыкаль лабораториясендә музейда сакланган кыл-кубыз, думбра, дәф, курай кебек уен коралларына өстенлек биргәннәр.

– Без үзебезгә кызык булган һәр төрки уен коралын фотога төшереп, сайтка урнаштырдык. Күп тә үтми, аларда уйнарга теләүче музыкантлар да мөрәҗәгать итә башлады. Гариза җибәрүчеләр арасында ун кешене сайлап алдык. Аларның кайсы гитарада, башка уен коралларында уйный, кемдер вокал белән шөгыльләнә. Бу тәҗрибәләре аларга борынгы уен коралларында уйнаганда да ярдәм итте, – ди Ильяс.

Шул рәвешле ун музыкант бер атна дәвамында Әлмәттәге музейда төрки музыка уен коралларында уйнауның асылына төшенә. Биредә махсус остаханәләр, ачык репетицияләр уза. Бер атнадан соң Әлмәт тамашачысына шушы җырлардан торган үзенчәлекле концертны тәкъдим итә алар. Дебют-тамашада Татарстанның атказанган артисты Эльмира Кәлимуллина да катнашкан. Егетләр төрки музыка уен кораллары белән беррәттән бәет, мөнәҗәт, такмак, озын көй кебек жанрларга да яңа сулыш өргән.

Илнар Фатыйхов

– Шул рәвешле «Татнефть» оешмасы, Казан музыкантлары, күргәзмә хезмәткәрләре һәм Әлмәт музыка көллияте студентлары эшчәнлегенең уртак нәтиҗәсе булып, төрле төрки жанрларга караган һәм бүгенге шигъриятенең актуаль темаларын колачлаган әсәрләр туды. Альбом борынгы Идел буе музыка сәнгате белән аның заманча яңгырашын берләштерде. Бу – уникаль материал. Аны тамашачы да бик җылы кабул итте. Концертны хәтта башка шәһәрләрдән килеп караучылар да булды. Төрки уен коралларында яңгыраган милли көйләребезгә ихтыяҗ бар. 4 ноябрь – Халыклар бердәмлеге көнендә – альбомыбыз барлык музыкаль мәйданчыкларга чыкты. Анда да тыңлаучыларыбыз күп. Олысыннан алып кечесенә кадәр кызыксына. Без моңа бик шатланабыз, билгеле. Төрки музыка уен кораллары ярдәмендә яңгыраган көйләребезне киләчәктә Россиядә генә түгел, дөнья күләмендә танытырга җыенабыз. Шушы зур эшне тормышка ашырырга ярдәм иткән Президент Мәдәни инициативалар фондына, «Татнефть» оешмасына зур рәхмәт, – ди Ильяс Гафаров.

«Татнефть» хәйрия фонды тарафыннан оештырылган проектлар җитәкчесе Павел Корчагин егетләрнең хезмәтен югары бәяли.

– Әлеге альбом борынгы төрки музыка уен коралларына яңа сулыш өреп кенә калмыйча, онытылып баручы көйләрне дә яңача яңгыраштa ишетергә мөмкинлек бирә. «Татнефть» оешмасы тарихи, мәдәни мирасыбызны саклауга, гомумән, зур игътибар бирә. Бу юнәлештә бик күп эшләнде, алга таба башкарачак эшләр дә бихисап. Шул ук музыка кораллары музеен гына алыйк. Егетләрнең шушы төрки уен коралларында башкарылган борынгы көйләрдән торган альбом чыгару ниятен дә «Татнефть» оешмасы шундук күтәреп алды, – ди ул.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

# ТӨРМӘ ТҮГЕЛ, САКЛЫК ЧАРАСЫ

## РОСГВАРДИЯНЕҢ ВЕДОМСТВОДАН ТЫШ САК ХЕЗМӘТЕ ИДАРӘСЕ 70 ЕЛЛЫГЫН БИЛГЕЛӘП ҮТТЕ

**Килешәсездер, бу хезмәт вәкилләре белән еш очрашабыз. Кайчагында аларны полиция хезмәткәрләре белән бутаучылар да бар. Чыннан да, эшчәнлекләре бер кебек бит: безне яклаучылар һәм саклаучылар. Бу оешма ничек барлыкка килгән? Ниләр белән шөгыльләнә? Бурычлары нинди? Росгвардиянең Татарстан буенча Ведомстводан тыш сак хезмәте идарәсе җитәкчесе урынбасары Марат СӘЛАХИЕВ белән әлеге сорауларга җавап табарга тырыштык.**

**:: Марат Фидаилевич, «ведомстводан тыш» дигән сүзләргә аңлатма бирегез әле.**

– Оешманың исеме структурага бәйле. Ведомстводан тыш сак хезмәте хезмәткәрләре үзләре саклаган объектларның штатында тормыйлар дигән сүз бу. Димәк, әлеге компанияләрнең җитәкчеләренә дә буйсынмыйлар булып чыга. Икенче төрле әйткәндә, ведомстволарга бөтенләй бәйле түгел, оешманың үз җитәкчелеге бар.

**:: Ведомстводан тыш сак хезмәтенең тарихына да күз салыйк әле. Ни дисәң дә, 70 ел аз вакыт түгел бит.**

– Бу бүлек 1952 елның 29 октябрендә СССР Министрлар Советы карары нигезендә оеша. Әмма шул ук вакытта аның тарихы бик еракларга барып тоташа. Тарихчылар фикеренчә, структураның нигезендә 1920 елда оештырылган сәнәгать милициясе ята. Чөнки Гражданнар сугышы вакытында милиционерлар нигездә җинаятьчеләрне тоту белән мәшгуль була. Ә дәүләт объектларын саклау буенча берни дә эш алып барылмый. Сәнәгать милициясе шушы бушлыкны тутырырга тиеш була. Алар үзләре саклаган объектта штатта торалар. Шуңа күрә дә, территория чикләреннән чыккач, сәнәгать милициясенең вәкаләтләре бетә. 1952 елда сакчылар Эчке эшләр министрлыгы системасына күчерелә. Нәкъ менә шушы көн ведомстводан тыш сак хезмәте оештырылуга нигез булып тора да инде. Татарстанда бу эшчәнлек ТАССР Эчке эшләр министрлыгы каршындагы зур булмаган бүлектән башлана. Соңрак мондый бүлекләр республиканың зур торак пунктларында оештырыла. Бүлекләр алдына, гражданнар белән килешүләр төзеп, аларның объектларын саклау бурычы да куела. Әйтергә кирәк, ил буенча беренчеләрдән булып нәкъ менә Татарстанда фатирларны сак сигнализациясе белән җиһазлый башлыйлар. Әлбәттә инде, шушы чор эчендә структура күп тапкыр үзгәрә. Мөгаен, тагын бер мөһим этап 2016 елда ведомстводан тыш бүлекләрнең полиция системасыннан Росгвардия сафларына күчерелүедер.

«Татар-информ»

**:: Әйтүегезчә, Ведомстводан тыш сак хезмәте тәүлек әйләнә тәртип саклау белән мәшгуль. Йортлар, мәктәпләр, сәүдә үзәкләре, завод-предприятиеләр – барысы да хәвеф-хәтәрне кисәтү төймәсе белән җиһазланган. Әмма фаҗигаләр була тора. Соңгы вакытларда Казан, Ижау шәһәрләре мәктәпләрендә булган вакыйгалар бигрәк тә авыр тойгы калдырды. Мондый хәлләр кабатланмас өчен ниләр эшләнә яки ниләр эшләргә кирәк?**

– Россия Хөкүмәте карары нигезендә, бүген Татарстандагы мәгариф учреждениеләренең барысы да – Росгвардиянең Ведомстводан тыш сак хезмәте контролендә. Әмма бу һәр укытучы үзе белән хәвеф-хәтәр турында кисәтү төймәсе йөртергә тиеш дигән сүз түгел. Мондый төймә бөтен бәладән дә коткара алмый, беренче чиратта килеп чыккан хәл турында хәбәр итү өчен генә кулланыла. Росгвардиячеләр теге яки бу вакыйга булган урынга шул секундта ук килеп тә җитә алмыйлар. Иң аз дигәндә дә, берничә минут үтәргә мөмкин. Минемчә, мәгариф учреждениеләрендә беренче чиратта керү ишекләрен ныгыту сорала. Моннан тыш сакчылардан – профессиональлек, вахтерлардан игътибар таләп итәргә, керү урыннарында контроль пункты оештырырга кирәк. Казан, Ижаудагы хәлләр Россиянең барлык төбәкләрендә дә сакны көчәйтергә кирәклеген күрсәтте. Форсаттан файдаланып, шунысын да әйтеп китик: персонал һәм балаларның тормышы өчен мәктәп директоры җавап бирә. Ул фаҗигаләрне булдырмас өчен, кабул ителгән планның үтәлешен күз уңында тотарга тиеш. Ә без, росгвардиячеләр, үзебезнең юнәлеш буенча алар белән бергәләп тикшерүләр үткәрәбез. Мәктәп бинасы хәвеф-хәтәрләрдән ни дәрәҗәдә сакланган? Беренче чиратта шул сорауга җавап эзлибез. Мөрәҗәгать итүчеләр булса, ярдәмгә килергә һәрвакыт әзер торабыз. Шул ук вакытта ата-аналар фикерен дә белешергә, алар белән уртак тел табарга кирәк. Керә торган урынга турникет куелгач, алар арасында: «Мәктәпне төрмәгә әйләндереп бетердегез инде», – диючеләр дә табыла. Ә фаҗига килеп чыккан очракта: «Кая карадыгыз? Ни өчен безнең балалар куркыныч астында?» – дигән сорау белән ябырылалар. Шуңа күрә аңлату эшләре бик урынлы. Менә сез, әгәр дә анда эшләмәсәгез, берәр заводка керә аласызмы? Юк. Бүгенге вазгыятьне искә алып, мәктәпләрдә дә шундый тәртип булырга тиеш.

**:: Сез тагын кемнәргә хезмәт күрсәтәсез?**

– Хөкүмәт биналарын, мәдәни һәм тарихи мирас объектларын, фатирларны саклыйбыз. Быел гына да сакка алынган объектлардан 39 мең сигнал килде. Әйтергә кирәк, экипаж әгъзалары объектлардан килгән хәбәрләр белән генә түгел, шул территориядәге полиция хезмәткәрләреннән кергән гаризалар белән дә эшлиләр. Бу җәһәттән росгвардиячеләр быел 4,5 мең тапкыр урыннарга чыктылар һәм 236 җинаять эшен ачыкладылар. Алар арасында талау, үтерү, машина куып китү һәм наркотикларга бәйле җинаятьләр дә бар. Ведомстводан тыш сак хезмәте күп тапкыр федераль эзләүдә булган җинаятьчеләрне дә тоткарларга булышты.

**:: Эш тәртибе ничек куелган?**

– Татарстан Республикасында тәүлек саен бер үк вакытта 79 патруль экипажы кизү тора башлый. Шуларның 29ы – Казанда. Һәр экипажның үз җаваплылыгындагы участогы бар. Маршрутлар шул территориядәге теләсә кайсы ноктага машина тиз арада барып җитәрлек итеп төзелгән. Росгвардия хезмәткәрләре шулай ук мәдәни һәм спорт чараларында тәртип саклыйлар, янгын вакытында коткаручыларга булышалар. Полиция патруль хезмәте булмаган очракта да, мәсәлән, төнлә, росгвардиячеләр үз эшләрен дәвам иттерәләр. Берәр хәл килеп чыкса, полиция хезмәткәрләре безнең экипаж белән элемтәгә керәләр. Республиканың күп кенә торак пунктларында җәмәгать тәртибен контрольдә тоту эшен нәкъ менә росгвардиячеләр үти.

**:: Росгвардия хезмәткәре нинди булырга тиеш?**

– Яхшы физик формада: тиз йөгерергә, җиңел тартылырга, атнага бер тапкыр ату күнекмәләрен камилләштерергә тиеш. Беренче карашка машина эчендә генә утырып йөреп кизү торуның авырлыгы юк кебек тоела торгандыр. Әмма җинаятьчене җәяү куып тотарга кирәкле урыннар да була бит. Өстәвенә нык, тәвәккәл булу да сорала. Безнең хезмәткәрләр күп тапкыр суга батучыларны, янгын эчендә калучыларны да коткарды. Профессиональ киллерны тоткарлау очрагы да булды. Сүз дә юк, физик яктан да, рухи яктан да сәламәт булу беренче урында тора. Моның өчен медицина каравы һәм психологик тестлар үтәргә кирәк. Шушы имтиханнарны үткәннән соң хәрби-табиб комиссиясе кандидатның бу эшкә яраклымы-юкмы икәнлеген тикшерә. Яраклы дип табылса, башта стажировка үтә, аннан соң гына эшкә алыну мәсьәләсе хәл ителә. Аңлашыла ки, хөкем җәзасына тартылган, алкоголизм яки наркоманиядән интеккән кешеләргә дә юл ябык дигән сүз. Яшь буенча чикләүләргә туры килү дә (35 яшькә кадәр) шушы исемлеккә керә. Таләпләр тагын да бар әле. Хезмәткә алынучы кешенең бер генә гражданлыгы – Россиянеке генә булырга, ул рус телен камил белергә тиеш. Кайсы милләттән булуы, нинди дин тотуы роль уйнамый.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

# Без капчыкта ятмый

**Беркетмәләргә ялган имза кую, капиталь ремонт вакытында акчаны тиешле максатларда файдаланмау, җыелыш җыймый гына карарлар кабул итү, идарәче компания директорларының торак-коммуналь хуҗалык акчасын үз максатларында файдалануы, җитәкчелек итүче туганнар арасында матди кызыксынулар булу. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә әнә шундый күңелсез хәлләр очрый, ди белгечләр. Татарстан Иҗтимагый палатасында узган «туры элемтә»дә алар кешеләрдән килгән сорауларга да җавап бирде.**

– Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә хокук, тәртип бозу очраклары күп. Әмма аның нәкъ менә коррупция очрагына туры килүен дәлилләр өчен вакыт кирәк. Әйе, мондый хәлләр узган елларда булгалады. Әйтик, Әлмәт һәм Чаллы шәһәрләрендә хезмәт вазыйфасыннан файдаланып, акча урлау очраклары булды, – диде Татарстан Республикасы Прокуратурасының коррупциягә каршы көрәш буенча законнар үтәлешенә күзәтчелек бүлеге өлкән прокуроры Роберт Вәлитов.

Бу тармакка кагылышлы сораулар шактый булса да, ике сәгатьлек «туры элемтә»гә шалтыратучылар алай ук күп түгел. Кемнеңдер соравы ачык һәм анык булмау, кемдер башка өлкәгә караган сорау белән мөрәҗәгать итү сәбәпле, шалтыратучыларның мәгълүматларын гына язып алдылар. Алга таба андыйларга Иҗтимагый палата әгъзалары җавап табарга ярдәм итәргә вәгъдә бирде.

Зәй районыннан шалтыраткан Галина ханым: « Йорт эчендәге җылыту системасын ремонтлаган өчен идарәче компания анда яшәүчеләрдән акча сорарга тиешме?» – дип сорады. Торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлеге башлыгы Марсель Низаметдинов аның соравына: «Әйе, мондый очракта чыгымнарны халык күтәрә», – дип җавап бирде.

Әлмәт шәһәрендә яшәүче Марина ханымны торак конторасы башкарган эшләрнең сыйфаты канәгатьләндермәгән.

– 7 нче торак конторасы подъездга ишекләр куйган иде. Узган ел 100 мең сум акчаны счеттан күчерсәләр дә, алар үзләренә йөкләнгән эшне начар башкарды. Ишекне буямады да, җылытмады да. Аннан соң безне «1 нче бистә» дигән идарәче компаниягә күчерделәр. Аларга мөрәҗәгать иткәч, калган эшләрне бушлай эшләргә теләмиләр. Өстәмә акча таләп итәләр. Бу очракта без нәрсә эшли алабыз? Кемгә мөрәҗәгать итәргә кирәк? – дип сорады ул.

Марсель Низаметдинов аңлатуынча, бу очракта акчаны алган торак конторасы эшне үзе ахырга кадәр җиткерергә тиеш.

Тагын бер шалтырату шулай ук Әлмәттән булды. Роберт Галләмов: «Торак конторасы үз вазыйфаларын тиешле дәрәҗәдә башкармый, – диде. – Алар быел йортны яхшылап карап чыгып, җитешсезлекләрне язып алырга һәм төзәтергә тиеш иде, тик барысы да сүздә генә булды. Тиешле документлар тутырылмаган. Ни өчен алар үз эшләренә салкын карый?»

Белгечләр бу сорауга төгәл җавап бирер өчен, барлык моментларны карарга кирәклеген әйтте һәм ачыклап бетергәч, шалтыратучы белән элемтәгә чыгарга вәгъдә бирделәр.

Зөһрә САДЫЙКОВА



Илдар Мөхәммәтҗанов

# ХА-ХА-ХАНӘ

*Шушы урында көләсе*

# ТАТАР КЛИПЛАРЫ ӨЧЕН ӘЗЕР ШАБЛОННАР

**Шаблон № 1**

Кыр. Мул игеннәр яки билдән печән. Бер кырыйда ялгыз каен үсеп утыра. Аның янында – моңсу җырчы. Каенга серләрен сөйли, коча, сыйпый. Кырда бик каты җил, әмма ул җырчыга комачау итми, тавышы бик көр һәм көчле чыга. Әйтерсең болын үзе үк – профессиональ эшләнгән студия. Җырчы, һичшиксез, ап-ак кәчтүмнән булырга тиеш! Аның ямь-яшел чирәмгә ышкылган киеме өчен тамашачы борчылып, җан атып утырырлык булсын.

**Шаблон № 2**

Җырчы егет берничә миллион сум торган машинасында шәһәрдән авылына кайтып бара (машинаны клип өчен арендага алырга мөмкин). Герой бер чишмә янында туктый, аның суын эчә. Киләсе тукталыш – зират. Монда егет якыннары каберен төзәтеп куя, бер мизгелгә хатирәгә чума. Менә авыл да күренде. Яшьлек дустым, синме бу?! Тракторың йөреп торамы? Әйдә, капка төбендә бер утырып, балачагыбызны искә алыйк әле, велосипедта йөргәнебезне аклы-каралы төсләрдә күз алдына китерик. Әмма озакка сузарга ярамый. Өйдә әти-әни көтә. Менә туган нигез. Чирәмдәге каз кәкәйләрен изеп, капка төбенә кыйммәтле иномарка килеп туктый. Пөхтәдән-пөхтә киенгән ак яулыклы әни (чулпылары гына онытылган) һәм театраль түбәтәйле әти 100 чакрым ераклыкта урнашкан Казаннан кайткан улларын каршы ала. Ярым рәсми рәвештә кул биреп исәнләшәләр, әни «дөрес күрештемме?» дип сораган сыман бер мизгелгә камерага карап ала. Җыр «бәхетле яшик әле җирдә» дигәнрәк сүзләр белән тәмамланырга тиеш.

**Шаблон № 3**

Төркия! Бу җырчы инде шунда хәтле үк барып клип төшерә алган – күрегез! Җыр текстында диңгез һәм чит ил турында бер сүз булмаса да, аптырамагыз. Матур бит! Мондый җәннәттә әни турында да, ялгыз каен турында да, туган авыл турында да клип төшерергә мөмкин. Менә диңгез балыклары – шуларга серемне сөйлим әле. Юк, әнә теге пальмага сөйлим. Клипта, һичшиксез, диңгез, шезлонг, квадроцикл, катерга тагылган парашют, «все включено» табыны һәм сөлгедән ясалган аккош булырга тиеш. Кунакханәнең ничә йолдызлы икәнен дә күрсәтергә онытмагыз – белсен фәкыйрьләр кайларда йөргәнегезне. Күп татарның бит чит илгә чыгу мөмкинлеге юк,



шуңа күрә бу клип белән сез аларга дөнья күрсәтеп, бик зур савап эшлисез.

**Шаблон № 4**

Бер кыз, каядыр ашыгып, өеннән чыгып чаба. Каршына бер егет очрый моның. Ниндидер кызыклы бер хәл килеп чыга шуннан. Мәзәкме, кызганычмы, ачу китергечме – белмим. Яшьләр һәркайсы үз юлын дәвам итә. Әмма миллион кешелек Казанда тагын бер 3–4 тапкыр шулай «очраклы» күрешә болар. Һәрвакыт нидер килеп чыга, нидер була. «Бу егет мине әллә күзәтәме, миңа бәйләнмәкчеме» дип шикләнә башлый кыз. Әмма клип инде ахырына якынлаша. Менә соңгы «очраклы» күрешү… Һәм! Менә сиңа мә! Теге егет бу кызның укытучысы (күршесе, дустының дусты, яңа җитәкчесе, клиенты һ.б.) булып чыга бит! Бу «шаккаткыч» борылышны клипның ахырына кадәр түзгән тамашачы гына күрә ала. Ай да режиссер, ай да…

**Шаблон № 5**

Авыл турында клип. Гадәттә, ул шушы авылдан чыккан иганәче акчасына төшерелә. Сабантуй, чишмә, тәрәзә йөзлекләре, капка төбе – әлеге клипның алыштыргысыз «реквизитлары». Авылның ак сакаллы һәм түбәтәйле бабае, һичшиксез, клипта күренергә тиеш. Кулына таяк тоттырыгыз, чалбар балагы йон оегына тыгып куелган булсын – типаж төгәл булырга тиеш. Авыл халкын күпләп төшерегез, әмма кадрдагы һәр кешене күз уңыннан үткәрергә кирәк. Кайвакыт клипка ялгыш кызыл борынлы якташлар да үтә чөнки. Видеодагы кәчтүм-чалбарлы абый кем дисезме? Клипның спонсоры шул була инде. Ул җитәкләгән оешманың логотибы да «очраклы» гына күренеп китә. Менә ул төзегән мәчет, менә Сабантуйда бүләк тапшыра, менә әти-әнисенә дип төзегән йорт капкасы төбендә алар белән кул биреп исәнләшә. Клипны бүген үк салым инспекциясенә декларация урынына илтеп тапшырырга була.

**Шаблон № 6**

Чибәр кызны студиядә төшерәләр. Моңарчы аны берничә көн соляриййда йоклатканнар булса кирәк. Кызның киемле җиренә караганда киемсез җире күбрәк. Ул хәтта оператордан да бераз уңайсызлана бугай. Оператор бит ул – тере кеше, ә тамашачылар – зәңгәр экранның теге ягында. Чибәркәйнең битендә калын катлам шпатлевка, гафу итегез, макияж. Җырчы кыз камерага сырпалана, аучы сыман карашлар ташлый, әйтерсең каядыр дәшә. Студиядә төшерелгән булуга карамастан, җырчының чәчләре җилферди. Әллә кемдер тәрәзәне ябарга оныткан, әллә студиянең җыештыручысы тузан суыртып йөри…




## *Шулай бервакыт Камал театрында*

**Мактауның да бар җае**

Бу хәлләрне безгә театр тәнкыйтьчесе Нияз Игъламов сөйләде. Берзаман спектакльдән соң сәхнә артына Ркаил Зәйдулла һәм Газинур Морат керә. Баш рольне башкарган актрисаның гримеркасын эзләп таба болар. Бик күп комплиментлар яудыралар артист ханымга. Ә чыгып киткәч, Ркаил әфәнде Газинур Моратка әйтеп куя: «Нишләп яхшылап мактамадың инде?» «Мактадым бит инде, тагын ничек мактыйм?» – ди Морат. «Мактау гына әз, бергә уйнаган партнерын хурларга иде, шулай итсәң, кешенең күңеле була», – дип аңлата Зәйдулла.

**Фил шиңгән**

«Хуҗа Насретдин» спектаклендә үзенчәлекле декорация бар – гелий белән кабартылган фил. Әмма берзаман ул спектакль барышында ук шиңә башлый. Техник хезмәткәрләр сәхнә артында чабулыйлар. Инде нишләргә? Өстәвенә фил актерлар өстенә төшә башлый. Тиз арада пәрдәне ябарга карар кылалар. Соңрак антрактта филнең тишек-тошыкларын ямыйлар да, ул кабат «рольгә керә». Шулай да була театрда.

**Дисциплина хәйләсе**

1962 ел. Яшь Марсель Сәлимҗанов үзенең диплом спектаклен куя. Әмма олпат актерлар яшь режиссерны бик тыңламыйлар, репетициягә соңга калып киләләр, үзләре теләгәнчә эшлиләр, дисциплина юк, кыскасы. СССРның халык артисты Хәлил Әбҗәлилов бу хәлне күрә дә бер хәйлә уйлап таба. «Әйдә, мин иртәгә репетициягә соңга калып килəм, ә син мине эт итеп сүк!» – ди ул яшь Марсельгә. Шулай итәләр дә. Әйтергә кирәк, Хәлил ага ул чакта иң абруйлы артист, өстәвенә орденнар кавалеры, ТАССРның Югары Советы депутаты. Икенче көнне ул, чыннан да, эшкә соңга калып килә. Марсель Сәлимҗанов аны рәхәтләнеп сүгә, тагын мондый хәл булса, рольдән алам, дип кычкыра. «Гафу итегез, Марсель Хәкимович, башка мондый хәл кабатланмас, миңа бик оят», – дип, Хәлил Әбҗәлилов башын аска ия. Хәйлә үз нәтиҗәсен биргән. Шушы хәлдән соң труппада катгый дисциплина урнашкан, ди.

**Бәтәч!**

Труппа мөдире Исрафил Сафин искә ала. «Гөргөри кияүләре» бара. Беренче бүлек тәмам. Берзаман Фирдәвес Хәйруллина үзен начар хис итә башлый. «Ашыгыч ярдәм» чакыралар. Сукыр эчәге, дип шикләнә табиблар. Инде икенче бүлектә нишләргә? Фирдәвес Хәйруллина урынына кем уйнар? Беренче катта йөрүче Раушания Юкачеваны эләктереп алалар да тиз арада Фирдәвес Хәйруллина урынына куялар. Берзаман сәхнәгә Раушания ханым килеп чыга. Вера Минкина аны күреп ала да шаккатып әйтеп куя: «Бәтәч! Безнең спектакльдә нишләп йөрисең?»

**Парижларга баруларым**

Уфа гастрольләре. Төн. Спектакльдән соң әле банкет та булган, шуңа күрә артистлар соңгарак калганнар. Автобус йөртүче кунакханәгә юлны үзе аңлаганча чамалап бара. Ул чакта навигаторлар юк әле. Асфальт та бетә берзаман, кыр юлы башлана, яңгыр да сибәләргә тотына. Караңгы, берни күренми. Кыскасы, адаша болар. Ерактарак бер юл билгесе ялтырый. Шунда таба китәләр. Күзләрен сөртебрәк карасалар, юл билгесендә «Париж» дип язылган! Баксаң, Башкортстанда шундый авыл бар икән. Таң ата дигәндә генә артистлар төялгән автобусны бер «КамАЗ» йөртүчесе күреп ала. Һәм Уфага таба дөрес юлны күрсәтә. Камал театры актерлары исә Парижга баруларын әле дә бик җылы искә алалар.

Илшат ЛАТЫЙПОВ ярдәме белән әзерләнде.

Гөлназ ШӘРИПОВА

## *Әбиләр «каникул»ы!*

*Каникуллар бетте диеп,*
*Әби җиңел сулады.*
*Шушы бер атна эчендә,*
*Күрмәгәне калмады.*

*Оныклары китү белән,*
*Кереп, диванга ауды.*
*Телевизорын кабызды,*
*Алъяпкычын да салды.*

*Ай-яй хәзерге балалар,*
*Дип сөйләнде үзалдына.*
*Телефоннар кулларында,*
*Эшләү юк уйларында.*

*Колакларында наушник,*
*Әйтәсең – ишетмиләр.*
*Көннәр буе йоклыйлар да*
*Төннәр буе йөриләр.*

*Әби, әби, бәлеш пешер,*
*Синең коймагың тәмле.*
*Мантый яса әле бүген,*
*Пиццаң да искитмәле.*

*Әбекәем, бүген кичкә*
*Булмас микән кыстыбый?*
*Ансын иртәгә пешерсәң,*
*Бүген өчпочмак ярый.*

*Тиен кебек тәгәрмәчтә,*
*Әйләнә әби көн буе.*
*Өйнең тәртибе калмады,*
*Әйтерсең пәри туе.*

*Һәркөнне мунча ягасы,*
*Чиста кием дә кирәк.*
*Ярый әле машина бар,*
*Калмас иде ул беләк.*

*Телик карау онытылды,*
*Телефон оныкларда.*
*Этләр булып арый әби,*
*Иртән ята йокларга.*

*Ә иртәсен шул ук мәхшәр,*
*Камыр кую, боткасы.*
*Ул арада чәен сорый,*
*Газиз карты, бабасы.*

*Пыштым гына сак-сак басып,*
*Атлап йөрешле өйдә.*
*Оныклар тәмләп йоклыйлар,*
*Очмый хәтта чебен дә.*

*Ә бүген ял, өйдә тынлык,*
*Оныклар китеп беткән.*
*Таба алмый әби яулыгын,*
*Оныклар җыеп киткән.*

*Урынында түгел, ахры,*
*Башмагы, йон ноские.*
*И Ходаем, кайда икән*
*Бабамның каштан мае?*

*Урыныннан күчкән бар да,*
*Ничек эзләп табарга?*
*Эзләмәгән җир калмады,*
*Тыкканнар соң кайларга?*

*Үзе эчтән генә сүгеп,*
*Күңеленнән сагынып,*
*Тәртип сала әби өйгә,*
*Оныкларын юксынып.*

*Исән-сау гына булыгыз,*
*Көтеп каламын сезне.*
*Я, әбиләр, әйтегезче,*
*Таныйсызмы үзегезне?!*

**Әз-мәз мәзәк**

Кызыл машинада йөрүче ирләргә кызыкмагыз, кызлар. Үзләре бүләк иткән бүләкне тартып алучылар бугай алар.

* * *

– Иртәгә ял көне бит. Әйдә, кафега барып, берне җиппәрик әле!
– Син үз акылыңдамы? Әйдә, бүген!

* * *

Бүген үз-үземә бикләндем. Кара әле, шәп икән бит анда!

**Фотофакт**

**Иске фотоаппаратлардан торган дөньядагы иң зур шәхси коллекция – Дилиш Пакер исемле әфәндедә. Ул Һиндстанда яши һәм гомере буе фотохәбәрче булып эшләгән. Бүген әлеге тупланмада 4425 данә ретро фотоаппарат исәпләнә. Их, хәзер аларның кадере бетте шул. Һәр кешенең кесәсендә – фотоаппарат. Ә элек! Сезнең дә бар идеме фотограф туганыгыз? Караңгы бүлмә, кызыл ут, «проявитель», «закрепитель» һәм… кер кыстыргычы белән бауга эленгән фотокәгазьләр кибә.**

## Көзге һәм депрессия

Көзгегә кара да көзге депрессиядән чык!

* * *

Мин бик күп антидепрессант кулланып карадым, миңа берсе генә ярдәм итте – акча.

* * *

– Тәк. Депрессия монда, күңел төшенкелеге монда, психоз монда. Ә «бетте баш» кайда? Ә-ә, күрәм, әнә йөгерә ул безнең янга.

* * *

Психолог белән тестлар уздыру – яхшы әйбер, әмма пыр тузып талашу арзанрак һәм нәтиҗәлерәк.

* * *

Йокларга яткач, иң мөһиме – ә мин бу тормышта нәрсәгә ирештем, дип уйлый башлаганчы йоклап китү.

* * *

Аерылышу һәрвакыт авыр. Бигрәк тә акча белән. Һәм әче таңнан урын-җиреңбелән.

* * *

Тормышта иң мөһиме – баланс! Банк картасындагы.

## Лайклылар һәм лаексызлар

- Гомер бик кыска, шуңа күрә аны теләсә нәрсәгә сарыф итмәгез. Һичшиксез, диванга ятып, социаль челтәрләр актарырга 2–3 сәгать вакыт табыгыз.
- – Директка ике ел җавап бирмәгәнем өчен гафу ит, кәефем начар иде.
- Кемнең аккаунтына кермә – бай тормыш. Безнең кебекләр өчен бюджетный социаль челтәр булдырыгыз әле.
- – Син социаль челтәрләр актарып утырган арада, синең сыйныфташың әнә өченчесен көтә инде.
- Вакытны карарга дип, телефоныма күз салган идем, бөтен нәрсәне карадым, әмма вакытны карарга онытканмын.
- Сторисларыңны кем караган дип тикшереп утырасыңмы? Ә кайчан бәби табарга уйлыйсың?




**Мач әйткән!**

**Чарли ЧАПЛИН, кино актеры һәм режиссер**

Әгәр сез бүген көлмәгәнсез икән, димәк, көнегез бушка узган дигән сүз.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Тираж – 6697 данә**
**Гомуми тираж – 15337 данә**

**Газетага сертификат бирелде** Заказ 367

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

**www.vatantat.ru**

**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**

**89179270040**

**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР

**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-73, 222-09-67** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы
**222-09-67** – фән һәм мәгариф
**222-09-64** – әдәбият, сәясәт һәм дин
**222-09-66** – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
**222-09-67** – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+